

Чистайда күргәннәрем

Чистай атаклы сәгать заводы, су исәпләгечләре белән генә таныш иде. Ә анда исә туристлар өчен бик күп кызыклы мәдәни-тарихи объектлар эшләп килә икән. Чистайда 144 мәдәни мирас объекты, 250 археология һәйкәле бар.

6 БИТ

Ташламалы бәядән языл!

11-21 май, 2017

Абунәче декадасы

П2430 индексы (пәнҗешәмбе саны) – 415 сум 86 тиен

П2395 индексы (атнага өч тапкыр)– 854 сум 28 тиен

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 19.05.2017 | № 53 (5815)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

БЕЗНЕҢ УРАМ БӘЙРӘМЕ

Бәйрәм арты бәйрәм үтте, ниһаять, безнең көн дә килеп җитте. Бүген – Татарстан матбугаты көне. Әлеге бәйрәм беренче татар газетасы «Нур» чыга башлаган көнгә туры китереп сайланган һәм инде 20 елдан артык билгеләп үтелә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Гаҗәп дәрәҗәдә кызыклы да, шул ук вакытта искиткеч җаваплы һәм авыр да һөнәр ияләре без – журналистлар. Республика, илдә барган хәлләрдән хәбәрдар булу гына түгел, район-авылларның да нинди кәеф белән яшәвен тою таләп ителә. Тиз һәм өлгер булырга, әмма шул ук вакытта «җиде кат үлчәп, бер кат кисәргә» туры килә. Кызык инде, тик журналистның һәркемдә һәм һәрнәрсәдә эше бар! Журналистның үткен каләме аша кемнәр, нинди темалар гына узмый! Мактаганда чамасын белеп мактарга, тәнкыйть утына тотканда объективлык турында онытмаска тиешсең. Кайвакыт безгә канатланып-дәртләнеп эшләр өчен: «Журналистларыгызның ярдәмендә өметләнәбез. Сез бит дүртенче хакимият», – дия-дия чын күңелдән ышанып, тегеяки бу проблемаларын чишүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән кешеләрнең күз карашларын күрү дә җитә. Ә ярдәмебез чыннан да тия. Укучыларыбыз, игелекле кешеләр ярдәме белән бергә кулга-кул тотынышып, балага юлыкканнарга матди ярдәм күрсәтүдән башлап, абунәчеләрне бүген һәм хәзер борчыган сорауларга тиз арада җаваплар табуга кадәр. Андый очраклар да алардан бигрәк үзебез күбрәк сөенмибез микән әле? Бәйрәм көннәрендә менә шундый матур уйлар, эшләгән эшләребез турында язу табигый хәлдер.

«Татарстан массакүләм коммуникация чаралары гражданлык җәмгыятенең мөһим институтына, тоткарлыксыз мәгълүмат чыганагына, киңәшчегә һәм республикада бара торган вакыйгаларның хәбәрчесенә әверелде. Күп очракта җирле матбугат чаралары халыкның гозерен хакимияткә җиткерергә ярдәм итсә, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарын гади халыкка якынайта, аларны борчыган мәсьәләләрне күрергә һәм тирәнрәк аңларга булыша. Көнүзәк мәсьәләләрнең тизрәк хәл ителеше күп очракта хакимият структуралары белән җирле масс-медианың конструктив эшенә бәйле була. Кадерле дуслар! Сез язмышыгызны үтә дә җаваплы һөнәр белән бәйләгәнсез, һәрвакыт вакыйгаларның алгы сызыгында торасыз, халык белән турыдан-туры аралашып яшисез. Җәмгыятьнең әхлакый-психологик торышы, асылда, аның бүгенгесе һәм киләчәге сезнең сүзнең никадәр үтемле булуына, үз вакытында әйтелүенә бәйле».

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның Татарстан Матбугат көне белән котлавыннан.

Шулай да әлеге көн безнең, ягъни көндәлек газета чыгаруда катнашкан журналистларныкы гына түгел, ә купсанлы укучыларыбызның, штаттан тыш хәбәрчеләребезнең дә уртак бәйрәме. Безнең белән бер дулкында булып, ирешкән уңышларыбызга сөенгән, кимчелекләребезне күреп, төзәтеп җибәргән, журналистларыбызның эшенә дөрес бәя биргән, «Шәһри Казан» белән дуслыкны саклаган укучыларыбыз, бу сезнең дә бәйрәм. Алга таба да ике арадагы дуслыкны югалтмасак иде. Россиянең барлык почта бүлекләрендә үтә торган Бөтенроссия язылу декадасы тәмамланып килә. Исегезгә төшерәбез, бу көннәрдә Россия почтасы каталогына кергән федераль басмаларга – 10, төбәкнекеләргә һәм җирле басмаларга – 15, башка агентлык каталогларындагы басмаларга 5 һәм 10 процент ташлама каралган. Форсаттан файдаланып калырга ашыксагыз иде! Газетаның икенче яртыеллыгына язылу исә июнь ахырына кадәр дәвам итәчәк.

Әлеге бәйрәм уңаеннан, тормыштагы вакыйгалары, хатирәләре белән уртаклашып редакциябез почтасына хатлар язган, һәрдаим матур, җылы, укылышлы язмаларын юллап торган штаттан тыш хәбәрчеләребезгә дә рәхмәт сүзләрен җиткерәсебез килә. Киләчәктә дә бергә һәм бердәм булсак иде!

Сүз уңаеннан, бүген Татарстанның Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин матбугат чараларының баш мөхәррирләре белән очрашып, дәүләт бүләкләрен тапшыра. Аннан соң «Пирамида» күңел ачу үзәгендә «Бәллүр каләм» бәйгесенең җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узачак.

Фәрит Мөхәммәтшин:

«Татарстан юлның башында гына»

Казанда «Россия – ислам дөньясы» саммиты бара

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Кичә Казанда «Россия – ислам дөньясы: KazanSummit 2017» (Казан саммит) дип исемләнгән IX халыкара икътисади саммит ачылды. Өч көн дәвам иткән чарада 50 илдән 2 меңнән артык кеше катнаша. Араларында дөньяның иң бай кешеләренең берсе The Kanoo Group Президенты Мишаль Хамид Кану, «Внешэкономбанк» рәисе Сергей Горьков, Ислам бизнесының халыкара ассоциациясе президенты Марат Кабаев һәм икътисад өлкәсендә танылган башка җитәкчеләр дә бар. Форум белән кызыксынучылар саны елдан-ел арта. Иң зур делегатлар Согуд Гарәбстаны, Судан, Төркия, Пакыстаннан килгән.

Быел форумның эшлекле өлешенә аеруча басым ясаганнар. Узган ел белән чагыштырганда, сәяси белгечләрдән тыш, саммитта эшмәкәрләр күп. Казан саммитының беренче көне дә Россиянең Ислам хезмәттәшлек оешмасына кергән илләрдән килгән яшь эшмәкәрләрнең форумы белән башланып китте. Чараның максаты — ике арадагы элемтәләрне ныгыту, катнашучылар тәкъдим иткән проектларны тикшерү. Иң кызыклы, отышлылары инвесторларга тәкъдим ителәчәк.

Быелгы чараның тагын бер үзенчәлеге – беренче тапкыр хәләл продукциядән торган күргәзмә оештырылган иде. Хәләл бренды астындагы продукт кулланучылар саны елдан-ел арта бара. «Хәләл бүген халыкара брендка әйләнә бара», – ди форум катнашучылары. Хәләл индустриягә кагылышлы сорауларга кагылышлы халыкара конференция ачылышында да Татарстанның Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин моны искәртеп узды.

– Планетаның 23 процент кешесе мөселман булып санала. Россиядә исә ислам динендә булган 20 миллионнан артык кеше яши. Хәләл ул ризык кына түгел, бу туризм, кием-салым, медиа, күңел ачу юнәлешләре дә. Татарстан бу өлкәдә юлның башында гына әле, әмма уртак хезмәттәшлек нәтиҗәсендә, дөнья базарында үз урыныбызны булдыра алдык, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Бүген Татарстанда 30лап предприятие хәләл продукция җитештерү белән шөгыльләнә. Аларның 20се бу эшкә ныклап тотынган.

Продукцияне халыкара хәләл стандартларга туры китереп җитештерү мөһим. Бу стандартларны булдыру үзе аерым мәсьәлә. Әйтик, кайбер мәзһәбләрдә кабул ителгән нәрсәләр икенчесендә кире кагыла. Берләшкән Гарәп Әмирлеге дәүләт министры Рәшид бин Әхмәт бин Фәһәд тә «ат итенә фикерегез ничек» дигәч, «ат итен ашыйлар дип уйламыйм», – дип гаҗәпләнеп калды. Ат итенең хәләл икәнен таный үзе. Әмма кайбер мәзһәбне тотучылар атны өнәп бетерми икән. Шуңа да бөтен җитештерүчеләр өчен дә бердәй стандартлар булдыру кирәк.

Чара кысаларында 30лап секция эшләячәк. Анда ислам финансларына кагылышлы темаларга, туризм, хәйриячелек һәм башка күп кенә кызыксындырган мәсьәләләрне уртага салып сөйләшәчәкләр.

Һәркем эшлекле очрашуларда үзен кызыксындырган өлкәне өйрәнергә тырыша, саммиттан файда алып, тәҗрибә уртаклашып калырга ашыга. Бөекбритания татарлары ассоциациясе рәисе Ринат Курамшин да милли костюмнардан күзен ала алмый.

– Казан саммитында беренче тапкыр гына катнашам. Без Лондонда эшләп килүче Россия – Британия компаниясен тәкъдим итәбез. Җиңел сәнәгать мода индустриясе, дизайн белән шөгыльләнәбез. Лондон – мода индустриясе алга киткән илләрдән санала. Бирегә толерантлык саклана, төрле милләт кешеләре үзара дус яши. Шуңа да безгә чит илдә Татарстан модельерларының эшен тәкъдим итү кызык булыр иде. Бу ике як өчен дә файдалы, мөһим, – ди Ринат Курамшин.

Ул форум кысаларында узачак мөселман модасы фестивален түземсезлек белән көтә. Моннан тыш, саммитка килүчеләр Казан марафонында катнашачак. «Россия – ислам дөньясы» кухня фестивален күрә алачак, шимбә көнне Изге Болгар җыенына бару да каралган.

Эльвира МОЗАФФАР.

Хәләл продукт – сыйфат бренды

Саммит кысаларында хәләл индустриянең RUSSIAHALALEXPO (Россия хәләл экспо) халыкара күргәзмәсе оештырылды. Беренче тапкыр гына оештырыла торган чарада хәләл сертификаты алган 50дән артык предприятие катнаша. Алар арасында үзебезнең Татарстанның гына түгел, Россия төбәкләре һәм чит илләрдән килүчеләр дә бар иде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин фикеренчә, чараны оештыручы «Хәләл» комитетына бик күп предприятиеләр мөрәҗәгать итә һәм комитет аларның ышанычын аклады. Мөселман кешесе өчен хәләл ризык белән туклану бик мөһим, шуңа да хәләл продуктка ихтыяҗ һәрчак булачак.

Күргәзмә ачылу тантанасында катнашкан Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов сүзләренчә, хәләл продукт ул ислам бренды гына түгел, ә бер зур сыйфат брендына әверелде һәм хәләл базарының киләчәге өметле.

Ямало-Ненецкий автоном округыннан килгән Вячеслав Сергатенко да шундый фикердә тора.

– Безнең «ЭКО ЯМАЛ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте төньяк кыргый болан итеннән ярымфабрикатлар җитештерә. Якын араларда хәләл продукция җитештерү цехы ачарга ниятлибез. Бу өлкәдә эш процессы бара. Соңгы елларда хәләл продукциягә ихтыяҗ артты. Шуны күз алдында тотып, хәләл ризык әзерли башларга кирәк дигән фикергә килдек. Ул гомуми продукциябезнең 15-20 процентын алып торачак. Хәләл продукцияне Көнчыгыш илләренә дә тәкъдим итеп була. Гомумән, чит илдә төньяк болан итен Россиягә караганда күбрәк кулланалар. Без аларга йөз тотачакбыз. Эксперимент рәвешендә хәләл продукция чыгардык һәм бу эшкә ныклап торып алынырга ниятлибез. Татарстанның Хәләл комитеты белән хезмәттәшлек итәчәкбез, – дип сөйләде ул безгә.

Кыргызстанның «Ата» кондитер фабрикасының эксперт буенча менеджеры Эмиль Камчибеков бирегә эшлекле контактлар табу, сату базарын киңәйтү, башкаларның тәҗрибәсе белән танышу өчен килгән.

– Россиядә мондый күргәзмәгә беренче генә тапкыр уза. Чарага үзебезне күрсәтергә һәм башкаларны күрергә килдек. Продукциябезне күрсәтәбез, танытасыбыз килә. Фабрикада тәүлегенә 75 тонна ризык җитештерелә. Баллы ризыкларыбыз Монголиягә, Кытайга, Иран, Таҗикстан, Казахстанга, Кавказга китә. Татарстан базарына да керәсебез килә, – ди ул.

Вологданың «Айсберри» туңдырма заводы исә хәләл продуктны яңарак кына чыгара башлаган.

– Махсус Казан өчен «Хәләл» туңдырма чыгара башладык. Тиздән супермаркетларда сатыла башлар дип өметләнәбез. Хәләл сертификатын Татарстанның «Хәләл» комитетыннан алдык. Хәләл туңдырма Казанда җитештерелми диярлек. Монда исә ислам кануннары белән яшәүчеләр бик күп, – ди заводның сату бүлеге җитәкчесе Лариса Барлева.

Күргәзмәдә хәләл ризыклардан тыш, хәләл хезмәтләр күрсәтү оешмалары да бар иде. «Хәләл» комитеты рәисе Марат Низамов сүзләренчә, проект дәвамлы булачак, аны киләчәктә зуррак мәйданда үткәрергә исәпләп торалар.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

46 Бөек Ватан сугышы ветераны яңа торак белән тәэмин ителәчәк. 16 майда Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының төбәкара вәкиллекләрендә сугыш ветераннары социаль ипотека килешүен төзи, төзелеп килә торган һәм төзелгән йортларда фатирлар сайлый башлады. Казан төбәкара вәкиллегендә генә дә бүгенге көнгә шундый 12 килешү төзелгән.

Ветераннар торак белән тәэмин ителә

Сүз уңаеннан, фонд адресына март аенда торакка субсидия алган Бөек Ватан сугышы ветераннары исемлеге җибәрелгән. Исемлектә 123 ветеран исәпләнә, аларның 47се торак шартларын фонд ярдәмендә яхшыртырга теләк белдергән. Казанда алар – 20 (берсе 16 май көнне фатир алган да инде), Биектауда – 1, Лаешта – 3, Яшел Үзәндә – 9, Чаллыда – 14. 2017 елгы төзелеш планына бу мәгълүматлар кертелмәгән булганлыктан, фонд фатирларны әзер яки төзелеп килә торган йортлардан бирү мөмкинлеген эзләгән. Моннан тыш, фонд ел саен алар аша фатир алучы һәр ветеранга 3 кв м бүләк итә.

Исегезгә төшерәбез, 2017 ел башыннан торак программаларын гамәлгә ашыру кысаларында гомуми мәйданы 132 415 кв м булган, 2 784 фатирга исәпләнгән 62 йорт тапшырылган. Шул исәптән 1094 фатирга исәпләнгән алты йорт (59 927 кв м) Казанда төзелгән.

Сөенечле һәм сагышлы китап

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын каршылаганда, «Казанские ведомости» газетасында башланган сугыш еллары хатирәләре сәхифәсе озын гомерле булды һәм үзе дә тарихи вакыйгага әверелде.

Рәдиф КАРАГАЙ

Дамир Бәдриев фотосы

ХӘТЕР

«Татар-информ» агентлыгында «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире Венера Якупова тарафыннан төзелгән «Путеводитель до Берлина» китабының икенче басмасын тәкъдим итү булды.

– Республикада сугыш ветераннары, тоткынлыкта һәм Ленинград камалышында булганнарны да исәпкә алып, 56 мең генә кеше калды. Һәр гаиләдә сугыш чоры белән бәйле истәлекләр бар. Аларны җәмәгатьчелеккә танытырга кирәк. Бу мәсьәләдә, Венера Якупова башлангычында, «Казанские ведомости» әһәмиятле эш башкара, – дип әйтеп үтте Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары – Татарстанның Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова.

– Бөек Җиңүнең 70 еллыгын каршылаганда, газета укучыларыбызга үзләренең гаиләләрендә сакланган сугыш елларына бәйле әйберләр һәм истәлекләр турында язып җибәрергә чакырган идек, – дип таныштырды Венера Якупова. – Тәкъдим киң яклау тапты. Газета укучыларыбыз хатлары тупланган беренче китап чыгарылды. Җиңүнең 72 еллыгына тагын бер тупланма чыгардык. Чит илләрнең кайбер сәясәтчеләре безнең Җиңүне «алырга» теләп тели. Кызыл Армия, элеккеге СССР халкы миллионнарча корбаннар бәрабәренә, фашистларны җиңеп, яулап алынган Җиңү ул. Бу китап ватанпәрварлек тәрбияләргә ярдәм итсен, яшьләр Бөек Ватан сугышы батырларын белеп үссен.

Казан Кремленең «Бөек Ватан сугышы» музей-мемориалы директоры Михаил Черепанов та Венера Якупова тарафыннан тупланылып чыгарылган китапларны хуплады.

– Тоткынлыктан качканда, минем бабай Михаил Ивановичны немец крестьяны яшергән, партизаннарга ничек барасы юлны күрсәткән. «Барлык немецлар да фашист түгел», – дип әйтә иде бабай, – дип сөйләде Михаил Черепанов.

Китапта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның әтисе Хәйрулла турында да истәлекләр бар. Халык сәнәгатен һәм һөнәрчелекне үстерү үзәге генераль директоры Нури Мостафаевның бабасы – кырым татары Амдиның гомерен сугышта «зажигалка»сы саклап калган. Арча районының Симетбаш авылыннан Нургали Шәфыйгуллин 20 яшендә үк Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән булган. Ул каты сугышларның берсендә яраланып егылган иптәшеннән байракны алып, сугышчыларны һөҗүмгә күтәргән. Герой исеме бирелмәсә дә, Нургали Шәфыйгуллин Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән.

– Әнием Мәрьям сугышта хәрби табиб булган. Ул бер батыр разведчикның гомерен өч мәртәбә саклап калган, ахырда аңа кияүгә чыккан. Аларның мәхәббәте турында елый-елый карый торган фильм төшереп булыр иде. Әнинең хәрби госпитальдә җитәкче булганлыгын бервакытта да әйткәне, мактанганы булмады, – дип, хатирәләре белән уртаклашты Россиянең атказанган һәм Татарстанның халык артисты, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең милли тапшырулар хезмәте җитәкчесе Лия Заһидуллина.

Венера Якупова гаиләсендә дә бабасы Низаметдин сугыштан алып кайткан немец плащ-палаткасы саклана. Әлеге хатирә турында китапта «Плащ-палатка» хикәятендә сөйләнелә. Венера Якупова – «100 историй о сувенирах», «Крымские татары, или Привет от Сталина», «Добро и зло российской журналистики» һәм башка китаплар авторы. Лия Заһидуллина, шушы хезмәтләргә ишарә ясап: «Венера Якупова, тарихи чынбарлыкны теркәп китаплар чыгарып, бик зур эш башкара», – дип, урынлы бәя бирде.

Казанның Яңа Савин районының Әмирхан урамындагы автомобильләр базары артындагы яшел зонада коточкыч антисанитария хөкем сөрә. Авиатөзелеш районына илтә торган дамба читенә бер машина йөге сыра савытлары китереп аударылган. Монысы әле бер хәл.

Әмирхан урамында – «яшел чүплек»

Хастаханә лабораториясеннән тизәк салынган йөзләгән шешәне юл читенә генә тондырганнар. Һәр агач-куак төбе бәдрәфкә әверелдерелгән. Автомобиль базарына килгән кешеләрнең шактые кече һәм зур йомышларын шушында гына башкара. Хәер, базар эчендә бәдрәф бар. Сазлыктан башлангыч алган елга–дренаж өсте пластик шешәләр, машина майлары савытлары һәм дөньяда булган башка чүп-чар белән тулган. Автомобильләрнең ватык пыялалары, тузган шиннар яр буена гына ыргытылган. Биредәге бөтен «зәхмәт» Казансу елгасына агып төшә.

Дамир БӘДРИЕВ.

ФОТО-ФАКТ


Автор фотосы

«Болгар академиясе динебез һәм илебез өчен кирәк»

tatar-inform.ru

Болгар ислам академиясендә укырга теләүчеләрнең саны шактый күп. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына биргән интервьюсында шулай дип белдергән. Әңгәмә барышында ул тиздән ачылачак академия эшчәнлеге турында да сөйләгән.

– Хәзер укытучылар белән актив рәвештә сөйләшүләр бара. Якын арада алар безнең республикага килә башлаячак. Укытучылар, билгеле, зур галимнәр, дөнья күләмендәге мөгаллимнәр булачак. Бөек кешеләрне бөек шәхесләр тәрбияләргә тиеш. Программага килгәндә, алар барысы да эшләнгән. Хәзерге вакытта дәреслекләрне килештерү бара, аннан алар бастырылачак. Укытучылар белән сөйләшү уздырабыз, уку йорты үз вакытында ачылачак, башкача була алмый, – дип ышанычын белдергән Камил хәзрәт.

Аның сүзләренә караганда, республиканыкылардан тыш, биредә чит ил белгечләре дә укытачак. Аның берсе – Габдеразак Сәиди. Ул инде бер еллап безнең республикада укыта. Күпләргә таныш. Шулай ук Сәйф әл-Асри дигән укытучы белән сөйләшүләр алып барыла. Сүриядән, Мисырдан галимнәр бар.

– Россия ислам уку йортлары турында сөйлибез икән, академия – шулар өстендә. Әгәр дә, әйтик, университетлар унлап икән, аны тәмамлаган кеше бакалавр дәрәҗәсен ала. Магистр яки доктор булу өчен, аңа безнең академиягә килергә кирәк булачак. Дөнья буенча башка укыту академияләре белән чагыштырабыз икән, алардан кайтыш булыр дип уйламыйбыз, әйбәтрәк тә булыр бәлкем, – дигән мөфти.

Хәзерге вакытта академиягә укучылар туплана. Укырга теләүчеләр шактый күп булып чыккан. Бирегә укырга керер өчен билгеле бер шартлар бар. Ул бакалавр булырга, югары ислам белеме алган булырга тиеш. Күп кенә мөхтәсибләр, имамнар Россия ислам университетын тәмамлаганнар, шунлыктан әзер укучыларыбыз күп. Биредә уку өчен Татарстаннан гына түгел, бөтен Россиядән, Кавказдан да, Идел буеннан да, үзәк районнардан да киләчәкләр.

– Академия динебез өчен дә, илебез өчен дә, Гарәп илләре белән элемтәләр өчен дә кирәк. Аның Татарстанда булуы бигрәк тә мөһим. Болгар ислам академиясен оештыруны Россия Президенты Владимир Путин да хуплады, – дигән Камил хәзрәт.

Мөфти сүзләренчә, 20 майда узачак Болгар изге җыенына баручылар академия төзелешенең нинди стадиядә булуын күрә алачак. Төзелеш эшләре көзгә тәмамланачак. 25 студент агымдагы елның 1 сентябрендә укый башлар дип көтелә.

ТАРИХЧЫ

МИЛЛИЯТ

Хәзер матурлык серләренә өйрәтүче, спорт, туризм, күңел ачу чараларын яктыртучы блогерлар буа буарлык. Ә яңа танышым Эмиль Шәйдуллин социаль челтәрләрдә тарих укыта. Моңа өстәп, ул әле Казан буйлап төрле кызыклы сәяхәтләр, квест-уеннар оештыра, мәчетләр тарихын барлый. Эмиль Казанның 155нче гимназиясендә тарих укыта. Яшь белгеч белем бирү системасында нибары – ике ел.

Алисә САБИРОВА

– Эмиль, матди кыйммәтләр заманында, ни өчен кешеләргә тарихи белем таратырга булдың? Ул бит сиңа акча да, дәрәҗә дә китерми.

– Мин укытучы бит. Хәзер балалар социаль челтәрләрдә утыра, бәлки минем төркем аша алар татар тарихыннан үзләренә нәрсәдер сеңдереп калыр. Укучыларга, Татарстанның танылган шәхесләре турында сөйләгез әле, дигәч, барысы да Муса Җәлил турында сөйли башлый. Башкаларын белмиләр чөнки. Үз төркемемдә Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин кебек шәхесләр турында язам, балалар шуны укый. «Лайк»лар артыннан кумыйм, минем өчен яшь буынга тарихны җиткерү мөһим. Үз тарихыбызны, килеп чыгышыбызны белмәсәк, без милләт буларак бетәчәкбез.

– Ләкин күп мәктәпләрдә Татарстан тарихын Россия тарихыннан вакыт калган очракта гына өйрәтәләр. Укытучылар да, ата-аналар да татар тарихыннан БДИ тапшырылмагач аңа салкын карый. Сезнең мәктәптә ничек?

– Россия тарихын өйрәнгән вакытта, шул ук чорда татарлар тормышында ни булганын карап китәбез. Киләсе уку елыннан Яңа Савин һәм Авиатөзелеш районнарында татар телле мәктәпләрдә Татарстан тарихын да кертәләр. V-VI сыйныф укучыларын аерым дәреслек буенча укытачаклар. Әлегә без китапсыз, презентацияләр ярдәмендә генә дәрес алып барабыз. Чыннан да, тарихны өйрәнү өчен 70 сәгать вакыт бик аз. Башта дөнья тарихы, аннан Россия тарихын өйрәнәбез. Татарстан тарихы буенча БДИ тапшырылмагач, укытучы төп басымны рус тарихына ясый инде. Миндә әле имтихан бирүче сыйныф юк, шуңа да бу проблема белән очрашмадым. Мин балаларга Казан тарихын төрле экскурсияләр оештырып өйрәтер идем дә бит, хәзер баланы кая да булса алып чыгу өчен дистәләгән документ тутырырга кирәк.

– Тарихны өйрәнгәндә нәрсәгә таянып эш итәсең?

– Өйдә зур китапханәм бар. Анда Казан тарихы, татарларга багышланган китаплар гына да 210га җитте. Бу өлкәдә Ризаэддин Фәхреддиннең «Минем хезмәттәшләрем йорт, мал, байлык туплаган вакытта, мин китаплар җыйдым» дигән сүзләренә таянам. Иң горурланган китабым – җиде томнан торган Татарстан тарихы. Галимнәрнең фикерләре белән танышу миңа кызык. Бу китапларда булган мәгълүматның күбесе интернетта юк.

– Соңгы вакытта «ВКонтакте» битендә күп мәгълүмат Казан мәчетләренә багышланган. Бу нәрсә белән бәйле?

– Эзләнүләремне билгеле бер юнәлештә алып барасым килде. Мәчетләр турында мәгълүматны һәр җомга көнне урнаштырам. Биредә фото, видео, җомга намазы аудиотасмасы, мәчет тарихы бар. Казанның сакланып калган иң борынгы мәчете – «Мәрҗани». Аннан бераз гына соңга калып, «Апанай» мәчете төзелгән. Бу ике мәчеткә кагылышлы бер кызыклы факт бар: алар икесе дә кыйбладан берничә градуска авышкан. «Мәрҗани» мәчетендә ул бик сизелмәсә, «Апанай»ныкында тайпылыш 25 градуска кадәр җиткән.

– Мәчетләр бер-берсеннән кай ягы белән аерыла?

– Иске мәчетләр авыл мәчетләренә охшаш: йорт, аның өстендә манара. «Мәрҗани», «Апанай», «Галия» мәчетләре бер стильдә төзелгән. Замана мәчетләре инде төрлесе-төрле стильдә. Шунысы кызык, яңа мәчетләргә караганда, искеләре буенча мәгълүмат күбрәк.

– Син шәһәр буенча да экскурсияләр оештырасың. Нәрсә белән җәлеп итә сәяхәтчеләрне Казан?

– «Казан – бик чиста, матур шәһәр, сезгә килгәч, Европага барып кайткан кебек булабыз. Юлларыгыз яхшы, тарихи биналар сакланган», – диләр. Чыннан да шулай бит. Безнең күзләр инде бу чисталыкка ияләшкән. Бездән «Тагын бер тапкыр Казанга килер идем», – дип китәләр.

– Күбрәк кайсы яклардан киләләр?

– Чиләбедән бик күп. Аларның үзләрендә дә татарлар белән бәйле географик атамалар шактый. Мәсәлән, Кече күл дигән күлләре бар. Мәскәүлеләр еш килә.

– Экскурсовод буларак әйт әле, Казанга сәяхәтләр өчен идеаль шәһәр дәрәҗәсенә җитәргә тагын нәрсә кирәк?

– Туклану урыннары җитми. Бездә әлегә урта хәлле кеше өчен татар кафелары аз. Төрек кафелары адым саен: бинасы да матур, ризыгы да тәмле, чагыштырмача очсыз да. Шундый ук татар кафелары оештырып булмыймы икән?

– Без белмәгән Казан нинди ул? Казан турында берничә кызыклы факт китер әле.

– Бауман урамының элеккеге исемнәрен кем белә? Башта ул Ногай урамы булган, соңрак Зур Проломная исемен йөрткән. Элеккеге Бауман урамы хәзер без ияләшкән, таш җәелгән урам булмаган. Анда ерганаклар, күперләр күп булган. Кремльгә кергән урамның Шейнкман проезды икәнен 90 процент кеше белми. Туристлар Казанның иң кечкенә урамы дип саналган Күнчеләр урамыннан йөрергә ярата. Хәзер «Кольцо» сәүдә үзәге торган урында элек балык сатканнар, сазлык булган.

Хәвеф чыганаклары: кышкы юлда – боз, җәйге юлда – балалар

ХӘРӘКӘТ ИМИНЛЕГЕ

Җәйге каникул якынлаша, мәктәп укучыларына сөенеч. Автоинспекторлар исә чын мәгънәсендә хәсрәттә, чөнки җәйге чорда балалар катнашындагы юл-транспорт һәлакәтләре кискен артып китә.

Дамир БӘДРИЕВ

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе мәгълүматларына караганда, узган елның июнь-август айларында балалар катнашында 175 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән. Аларда җиде баланың гомере өзелгән, 181е төрле авырлыктагы имгәнүләргә дучар булган. Республикада быелның дүрт аенда 16 яшькә кадәрге балалар катнашындагы 141 аварияда ике баланы гомерлеккә югалттык һәм 146 баланы имгәтергә өлгердек инде.

Юлларда балалар катнашындагы фаҗигаләрне чикләү максатында, Татарстанда 5 июньгә кадәр «Игътибар–балалар!» акциясе бара. Әлегә профилактика чарасы вакытында кечкенә пассажирларны йөртү, җәяүлеләргә өстенлекле юл бирү кагыйдәләре үтәлешенә аеруча игътибар юнәлтеләчәк. Мәктәпләрдә һәм соңрак балаларның җәйге сәламәтләндерү лагерьларында лекцияләр, юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнүгә корылган викторина-уеннар оештырылачак.

Транспорт чарасы нинди конструкциядә булуга карамастан, аларда балаларның иминлеге шартлары катгый үтәлергә тиеш. Бу таләп башкарылмаса, балаларны йөртү тыела. Җиңел автомобильдә, мәсәлән, 12 яшькә кадәрге баланы махсуслаштырылган урындыкта йөртү мәҗбүри. Кагыйдәне үтәмәсәң, 3 мең сум штраф. Быелның дүрт аенда шушы кагыйдәне бозганы өчен, республикада 8 мең кеше административ җаваплылыкка тартылган.

Юл билгесе торган һәм «зебра» тамгасы төшерелгән урыннарда җәяүлеләргә юл өстенлеге бирмәү республикада «зәхмәтле чир» төсмере алды шикелле. Транспорт чарасын идарә итүчеләр армиясеннән, шушы кагыйдәне бозганы өчен, 24 мең «әтәч» тотылган инде. Җәяүлегә юл бирмәгән өчен 1500 сум штраф кайберәүләр өчен 1 сум 50 тиен генә кебек. Казанның Яңа Савин районындагы 7нче гимназиясенә иртә-кич кыйммәтле машиналарда балаларны китерәләр һәм алып китәләр. Лаврентьев урамындагы ишегаллары юллары «Париж-Дакар» автоузышын хәтерләтә. Яңа Савиндагы 7нче гимназия һәм 23нче мәктәп янәшәсендәге ишегаллары юлларында «зебра» тамгасы кыш дәвамында ашалып беткән. Ут капкандай чабышкан машиналар руле артындагыларның кайберләре «җәяүле» билгесен күрми дә. Укырга җәяү баручы башлангыч сыйныфлар укучылары юл аша чыгарга куркып басып тора, бичаралар. Кыйммәтле машинадагы «әтәч» сабыйга юл бирми. Монда 24 мең кагыйдә бозучыны бер атнада җыярга була.

ЮХИДИ идарәсе ата-аналарны да балаларга юл хәрәкәте кагыйдәләрен актив өйрәтергә, балаларны күз уңыннан ычкындырмаска чакыра. Татарстанда быелның дүрт аенда 16 яшькә кадәрге балалардан 5 меңгә якын малай һәм кыз юл кагыйдәсен бозганда тукталган. Теләсә кайсы урыннан юл аша чыгу, юл буенда уйнау фаҗигале тәмамланырга мөмкин. Хәзер авылларда да асфальт. Мәктәпкәчә яшьтәге сабыйларның «балалар бакчасы» – урамдагы юл. Кайсысы велосипедта, кайсысы самокатта, кайсысы «таяк ат» иярләп йөгерә. Автоинспекторлар тикмәгә генә хәсрәтләнми инде ул. Игътибар, балалар! Бу кисәтүне профилактика акциясе узганнан соң да онытмыйк.

Аванс белән бирелгән таныклык

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

«Беркайчан да берни дә сорамагыз! Беркайчан да һәм берни дә, һәм бигрәк тә үзегездән көчлерәкләрдән. Үзләре барысын да китереп бирерләр!» Булгаковның «Мастер и Маргарита» романында иблис туеннан соң Воланд Маргаритага шулай ди. Минем рәсми төстә язучы итеп танылуым, ягъни Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп сайлануым – бөек язучының бу сүзләре хак булуына тагын бер дәлил.

2007 елның декабрендә Татарстан Язучылар берлегенең ул чактагы рәисе Илфак Ибраһимов шылтыратты:

– Сәлам, Равил!

– Исәнмесез.

– Карале, синең шушы араларда Казанга киләсең юкмы?

– Алай бик ашыгыч эшләр юк югын, тик бер урап кайтсаң да комачауламас иде.

– Алай булгач, килеп чык әле син, Равил! Сөйләшәсе сүз бар иде.

– Нәрсә турында?

– Килгәч, килгәч! Көтәм, яме?

Казанда Илфак әфәнде керү белән турыга ярып салды. Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге рәисе Вахит Имамов башка эшкә күчәргә исәпләп йөри икән.

– Исемлекне алып, бөтен булган әгъзаларны тикшереп чыктык. Әйдә, син алын әле бу эшкә, – ди рәис. – Риза булсаң, бүгеннән Язучылар союзына алу эшен башлыйбыз. Бүген как раз драматургия секциясе утырышы була. Каршы килмәсәң, синең иҗатыңны тикшерәчәкләр.

– Кемнәр була соң анда? – дим, аптырап.

Санап китте бу. Араларында пьесаларымны укыган кешеләр булуы шикле. Әйттем шигемне.

– Юк өчен борчылма, алар синең иҗатны белә, – диде Илфак әфәнде.

Кердем секция утырышына. Данил Салихов «Хәят»не караган булып чыкты:

– Егетләр, безнең татар драматургиясенә бик үзенчәлекле, беркемне дә кабатламый торган, үз стиле, үз алымнары белән эш итә торган бик талантлы каләм иясе килә. Мин моны шатланып әйтәм. Аның «Хәят»е – татар халкының иң күркәм, иң матур якларын бүгенгә тамашачыга бик шәп итеп күрсәтә торган спектакль.

Рәдиф Сәгъди «Земфирәкәй, сылуым, аппагым»ны күргән икән. Тик ул нишләптер пьеса турында түгел, спектакльне куйган режиссер турында сөйләде.

Хәбир Ибраһимов драматик әсәрләремне укымаганы һәм күрмәгәне турында «честно признался». Ләкин ул «Бисәпит» хикәясе турында сөйләде. (Карале, малай, «Идел»дә басылганына 15 ел үткән, ә ул әле хәтерли!) Ләбиб Лерон башка хикәяләр турында җылы сүзләр әйтте, Вакыйф Нуриев «Татарстан яшьләре»ндә басылган журналистик язмалар турындагы фикерен яңгыратты.

Драматургия секциясе җитәкчесе Мансур Гыйләҗев ни мәкаләләрне, ни хикәяләрне, ни пьесаларны укымаган, спектакльне күрмәгән бердәнбер кеше иде. Ул, гомумән, утырышка Равил Сабырҗан дигән кешенең шигырьләр җыентыгын тотып килгән иде. Тик ул да әйтер сүз тапты:

– Егетләр, әгәр кеше үзе язган пьеса белән профессиональ режиссерны кызыксындырып аны сәхнәләштерүгә ирешкән икән, димәк, ул драматург инде. Монда башка сүз әйтеп торуның кирәге дә юк.

Кыскасы, бертавыштан мине Язучылар союзына әгъза итеп алырга тәкъдим итәргә, дип «карар кылдылар».

Хуш. Өч-дүрт рекомендация кирәк булачак, диделәр. Берсен үзем язармын, диде шундук Вахит Имамов. Аның тәкъдимнамәсендә мондый юллар да бар иде. «Равил Сабыр үзенең тәүге әсәрләре белән республика газеталарында һәм журналларында моннан ун ел чамасы элек үк күренә башлаган иде. Әдәбият сөючеләр аның аеруча «Гасыр романы» дип тамгаланган эксперимент язмада биш авторның берсе булып катнашуына игътибар итте. Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Леоннар катнашкан ул язма чын роман булудан шактый ерак торса да, яшь-яшь егетләрнең әдәбият мәйданын яңа алымнар белән сынап каралары, яңа жанр юнәлешендә эзләнүләре барыбер дә кызык, тынгысызлык һәм әдәби талант чагылышы иде».

Күптәнге дусларым Ркаил Зәйдулла белән Ләбиб Лерон да рекомендация яздылар. Өч рекомендация җитә дисәләр дә, мин Туфан абый Миңнуллинга да мөрәҗәгать итәргә булдым. Бик сирәк бирә ул рекомендацияләрне, диделәр. Миңа тагын да кызыграк булып китте. Миңа бирер микән?

Монда шунысын да ассызыклап үтәргә кирәк, Туфан абый миңа аталарча бик җылы мөнәсәбәттә иде. Кайчан шылтыратсам да (гадәттә мин аңа журналист вазифаларын үтәп шылтырата торган идем), сорауларыма бик тәфсилләп җавап бирә иде. Дүрт пьесамны укып чыкты, үз фикерләрен, киңәшләрен әйтте. «Абага алмасы ачы була» пьесасын мин аның киңәше белән яңадан эшләдем.

Туфан абыйның номерын җыеп, гозеремне әйттем. Озак кына дәшми торды да бу: «Ярар инде, драматург та булгач, язып бирми булмас. Тик үпкәләмәссең инде, бездән дә шәбрәк яза дип рекомендация бирә алмыйм», – диде.

Болай дип язган: «Равил Сабыр атлы язучының Татарстан Язучылар берлегенә әгъза булып керәсе килә икән. Килә икән, керсен, дип әйтү ягында мин. Инде аның шактый гына хикәяләре матбугатта чыккан. Әмма мин аны драматург буларак тәкъдим итәм. Билгеле, аның пьесалары театрларда яңа куела башлады. Бер пьесасы («Хәят») Чаллы драма театрында куелды. Әйтүләренә караганда, зур уңыш белән бара. Мин аның өч-дүрт әсәрен (пьесалар) укыдым. Жанрның серләрен белә. Алла боерса, драматург чыгачак. Тик күп сүзлелектән дәваланырга кирәк. Уңышлар телим».

Идарә утырышын 25 гыйнварга, ягъни миңа 34 яшь туларга ике көн алдарак билгеләделәр. Бардык Казанга. Идарә утырышы башланыр алдыннан дус-ишләр белән хәл-әхвәлләр, дөнья яңалыклары турында гәпләшеп алдык. Берзаман Марсель Гали килеп чыкты да, ияген югары күтәреп миңа дикъкать белән карап торганнан соң: «Син бодай да биек малай, биленңе алай туры тотма, сыгылмалырак бул. Никадәр генә биек булсаң да, мондагы кайбер кешеләрдән өстәрәк булып булмый», – дип куйды.

Утырыш башланды. Бераздан мине дә чакырып кертеләр. Вакыйф Нуриев автобиографиямне һәм Ләбиб Лерон язган рекомендацияне укып чыкты. Аннан соң сүзне Туфан абый алды:

– Мин Равилгә рекомендацияне аванс белән бирдем инде. Ләкин бу Равил Язучылар союзына кабул итәргә лаексыз дигән сүз түгел. Аңарда драматург өчен иң кирәкле сыйфат бар: ул драматик ситуацияне кора белә. Миңа «Яңа татар пьесасы» конкурсына килгән берничә пьесаны укып чыгарга биргәннәр иде. Араларында театрның ишеге кайсы якка ачылганын да белмәгән кешеләр, пьеса яздым, дип җибәргәннәр. Равилнең пьесасын чаллылар куйды инде, әйтүләренә караганда, уңыш белән бара, тагын ике пьесасын куярга алганнар. Алла боерса, алары да куелыр. Мин Равил әле без исән чакта шәп-шәп әсәрләр язып, аларны театрларыбыз куеп, безне сөендерерләр дип ышанам. Аңарда бер генә кимчелек бар, ул барлык яшь драматургларга да хас – бик күп сүз яза!

– Туфан абый, – дип сүзгә кушылды Ркаил. – Менә Чеховның «Три сестры» пьесасы куелып ятканда, аның янына шул спектакльдә Андрей Прозоровны уйнаган артист килә. Анда аның хатыны турында бер битлек озын монологы була. Антон Палыч, ди артист, бу хәтле сүзне сәхнәдән сөйләп бетереп булмый бит инде, әзрәк кыскартып булмыймы аны? Чехов, уйлап карармын, дип кайтып китә. Икенче көнне бер бит кәгазь күтәреп килә дә бу, артистка суза. Тегесе күз салса, озын монологтан бер генә җөмлә калган ди: «Жена есть жена».

(Чынлыкта исә Чехов пьесасында бу репликадан соң тагын дүрт-биш җөмлә бар әле.)

– Чеховны мин аны гомумән драматургка санамыйм! – дип кызып китте Туфан абый.

– Ул үзе дә бит башкаларны драматургка санамаган, – дип кыстырды Марсель Галиев.

Ркаил, гадәтенчә, мыек астыннан гына елмаеп, ишетелер-ишетелмәс кенә мыңгырданып:

– Бөтен дөньяның исе китә бит, шуңа гына әйтүем, – дип урынына утырды.

Ә Вахит Имамов торып басты:

– Менә Туфан абый бик күп сүз яза, диде. Ә без күптән түгел «Мәйдан» журналының Чаллы язучылар оешмасы юбилеена багышланган санын чыгарган идек, шунда Равил үзенең бер хикәясен тәкъдим итте. Укып чыктым: бер сүзен генә түгел, хәтта өтерен дә кыскартып та, өстәп тә булмый инде менә!

– Алайса, була инде! – диде Туфан абый.

– Моны хәзер бертавыштан кабул итәләр, – дип Камил Кәримов күршесендә утырган Вакыйф Нуриевка фаразын әйтте.

Аннары яшерен тавыш бирү булды, шундук нәтиҗәләр белән таныштырдылар: «18 бюллетень таратылды, 18 кеше тавыш бирде, 18е дә «за».

Илфак Ибраһимов мине Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителүем белән тәбрик итте. Мин рәхмәт әйтеп чыгып киттем.

Шулай итеп, бер китабым да басылып чыкмаган килеш, рәсми рәвештә язучы булып куйдым. Беркемнән сорамыйча, беркемгә ялынмыйча. Ә иң кызыгы шунда: бераздан Чаллы язучылар оешмасының чираттагы отчет-сайлау җыелышы булды һәм анда җитәкче итеп... кабаттан Вахит Имамов сайланды.

ЧИСТАЙДА КҮРГӘННӘРЕМ

Үзем өчен яңа шәһәр ачтым. Чистай миңа атаклы сәгать заводы, су исәпләгечләре белән генә таныш иде. Ә анда исә туристлар өчен бик күп кызыклы мәдәни-тарихи объектлар эшләп килә икән. Чистайны «Мәдәни Афина» дип йөртүләрен монда килгәч кенә ишетеп белдем. Биредә 144 мәдәни мирас объекты, 250 археология һәйкәле бар. Сакланып калган тарихи объектларның төрлелеге белән Чистай 41 россиякүләм тарихи авыллар исемлегенә кергән. Шәһәр читендә федераль дәрәҗәдәге археологик һәйкәл – борынгы Болгар шәһәре Җукәтау калдыклары урнашкан. Сәүдәгәрләр каласы буларак та танылган. Шуңа да ул Казан губернасында Казаннан кала икътисади яктан үсеш алган икенче шәһәр саналган. Биредә 1886 елда төзелгән Суэтем башнясы да сакланган. Башня төзү өчен акчаны Чистайның иң бай сәүдәгәре – икмәк белән сату итүче Василий Челышев биргән, ул шәһәрдә меценат буларак та танылган кеше була.

Автор фотолары

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

МУЗЕЙЛАР

Бөек Ватан сугышы елларында биргә Советлар Союзының үзәк һәм көнбатыш өлкәләрендә яшәүчеләр һәм бик күп сәнәгать предприятиеләре эвакуацияләнә. Шәһәр халкы саны ике тапкырга артып китә. 1941-1943 елларда биргә 200дән артык язучы һәм мәдәният эшлеклесе эвакуацияләнгән. Шул рәвешле Совет язучылары берлеге бүлеге ачылган. Чистайдагы Әдәби фонд интернатында 500ләп язучы баласы, шул исәптән Тимур Гайдар, Алеша Баталов, Игорь Можейколар яшәгән. Биредә Борис Пастернак, Леонид Леонов, Анна Ахматова, Константин Тренев, Николай Асеев, Михаил Исаковский, Константин Федин, Мария Петровых, Александр Гладков, Александр Фадеев һәм башка тагын бик күп язучылар дөнья һәм рус әдәбиятының алтын фондына кергән әсәрләр язган. Чистайда Борис Пастернак үзенең атаклы «Доктор Живаго» романын яза башлаган, Шекспирны тәрҗемә иткән.

Язучы Борис Пастернакның нибары ике музее бар. Аларның иң беренчесе Чистайда ачылган. Музей директоры Любовь Демченко сүзләренә караганда, биредә ел саен ун мең турист булып китә.

– Канададан килгән бер фермер, музейга килеп керүгә үк, елый башлады. Без гаиләбез белән «Доктор Живаго» киносын яратабыз. Пастернакның үз теләнгә язган романын укыр өчен, мин махсус рус телен өйрәндем дип сөйләде ул безгә. Рус әдәбиятын яратучылар биргә керми калмый, – ди ул.

Борис Леонидовичның музее ул яшәгән йортта ачылган. Монда аның үзе киеп йөргән итеге һәм пәлтәсе саклана. Кара постау пәлтә 1940 елларда язучының икенче хатыны Зинаида Николаевна үгетләгәч кенә тегелгән. Музей коллекциясен җыю һәм аны тулыландыру белән актив рәвештә язучының улы һәм килене шөгыльләнгән. 2015 елда музейдан ерак түгел урнашкан бакча эченә Пастернакның һәйкәле куелган.

Шәһәр тарихы музее 1921 елда оешкан һәм атаклы сәүдәгәр Алексей Подуруев йортында урнашкан. Биредә туристлар өчен кызыклы булган экспонатлар шактый, аларның кайберләре:

✓ 1966 елда Җукәтау шәһәре урынында табылган көмеш акчалар хәзинәсе.

✓ Рубин төсендәге ташлар белән бизәлгән Корьән савыты.

✓ Варшаваның атаклы Фраже фабрикасында эшләнгән самавыр ТАССРның атаклы табибы Самуил Самойлов гаиләсендә кулланылган.

✓ 1902 һәм 1909 елда эшләнгән агач велосипедлар. Аларны Чистопольские Выселки авылы кешесе Николай Мельников эшләгән. Беренче велосипед йөрергә җайсыз булганлыктан, бөтенләй кулланылмаган. Ә икенчесендә Николай Мельников егерме елдан артык йөргән.

✓ 122 төр кош йомыркасы. Ул музейга нигез салган натуралист һәм археолог Александр Буличның шәхси коллекциясендә сакланган булган.

Шәһәр тарихы музеенда узган ел 40 мең турист булган.

Туристлар өчен «Укытучы йорты» мемориаль музее да ачык. Музей урнашкан бинада Бөек Ватан сугышы елларында Язучылар берлеге бүлеге эшли. Кайбер язучылар берлеккә нәкъ менә шушында кабул ителгән. Укытучы йортының актлар залында пьесалар да сәхнәләштерелгән.

Чистайда күптән түгел генә Музей-күргәзмә комплексы ачылган, ул Бөек Ватан сугышына багышлана. Киләчәктә биредә «Минем бәхетле балачагым» дигән совет заманы уенчыклары күргәзмәсен ачу ниятләнелә.

Чистайның Яуширмә авылында Гаяз Исхакый музее эшли. Язучы туган йорт сакланмаган, шуңа да аның музее сәүдәгәр Сәйфетдин йортында урнашкан. Биредә 3000гә якын экспонат саклана.

Музейларның барысы да шәһәрнең тарихи өлешендә урнашкан. Алар янәшәсендә үк аерым бинада Музей сувенирлар салонын да ачканнар. Ул шулай ук сәүдәгәр Михаил Мельников йортында урнашкан. Туристларга биредә ике меңнән артык төрдәге сувенир продукциясе тәкъдим ителә. Шунда ук атаклы Чистай сәгать заводы продукциясе дә бар. Сатучыларның сүзләренә караганда, кунаклар «Командирские» и «Амфибия» маркалары сәгатьләрен яратып ала. Кварц һәм механик сәгатьләрнең бәяләре – 850 сумнан 5 мең сумга кадәр. Шунысын да истә тотарга кирәк: монда акча карточка белән кабул ителми.

Музейларга керү бәяләре: балаларга – 100, олыларга – 150 сум.

МУЗЕЙЛАР САНЫ АРТАЧАК

Киләчәктә Чистайда Сәяси репрессия корбаннары музее ачарга уйлыйлар. XIX гасыр уртасында төзелгән Чистай төрмәсендә бөтен дөньяга танылган совет диссидентлары да утырып чыккан. 1978-80нче елларда Мәскәүдә Олимпиада уздырыр алдыннан, зур чараны уткәрергә комачаулый күрмәсеннәр дип, сәяси тоткыннарны кая да булса урнаштырып тору җаен эзли башлаганнар. Эзли торгач, Чистай төрмәсенә тукталганнар. Шул рәвешле сәяси тоткыннардан торган зур этап Чистай төрмәсенә китерелә.

Киләчәктә Чистайда атаклы рус химигы Александр Бутлеров һәм сәүдәгәрләр музеен ачарга җыеналар.

ИҢ БОРЫНГЫ МӘЧЕТ

Казандагы кебек, биредә дә Иске Татар бистәсе бар. Анда республиканың иң борынгы мәчетләренең берсе – 1817 елда салынган «Нур» мәчете эшләп килә. Мәчетнең имам хатибы Мөхәммәт Кыямов сүзләренчә, «Мәрҗани» мәчете кебек үк, аның ишекләре беркайчан да ябылып тормаган.

– Монда яртгы гасыр имам булып Мөхәммәтзакир Мөхәммәткамалов эшләгән. Әлеге татар сәүдәгәре турында Россиядә генә түгел, Европада да ишетеп белгәннәр. Дин әһеле дә, укытучы да, мәгърифәтче дә булган Мөхәммәтзакир Мөхәммәткамаловның Коръәнне яхшы белүе дә билгеле. Ул ачкан «Камалия» мәдрәсәсендә Ризаэддин Фәхреддинов, Фатих Кәрими, Галиәскар Гафуров-Чыгтай һәм Гаяз Исхакый укыган. Сәүдәгәр төзеткән «Әмирхания» кызлар мәдрәсәсендә Габдулла Тукайның мәхәббәте Зәйтүнә Мәүлудова белем алган, – дип сөйләде ул безгә.

200 еллык тарихында мәчет өч тапкыр янган.

«Нур» мәчетеннән читтә композитор Софья Гобәйдуллина туган йорт тора. Шунда ук «Аеклык трактиры» исеме алган бина урнашкан. Биредә чәй һәм баллы ризыклар гына тәкъдим ителгән. Сугыш елларында Иске Татар бистәсендә безгә Кир Булычёв тәхәллүсе белән билгеле булган язучы-фантаст Игорь Можейко да яшәп алган. Аның әнисе монда авиадесант мәктәбе директоры булып эшләгән.

Фестиваль яңа йолдызлар кабызды

Казанның Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концертлар залында узган Рәшит Ваһапов исемендәге гала-концертта XIII халыкара татар җыры бәйгесе җиңүчеләрен бүләкләделәр.

Шамил Абдюшев фотосы

МӘДӘНИЯТ

Быел 34 артист һәм дүрт коллектив номинант буларак игълан ителде.

Ә фестивальнең Гран-приена яшь җырчы, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты студенты, тамашачы каршында инде үзенең сольный концерты белән имтихан тоткан Рәнис Габбазов лаек булды. Яңа тавышлар, виртуоз музыкантлар, тамашаның мөхтәрәм кунаклары – бу көнне тамашачыларга әнә шуларны күрергә насыйп булды.

Гала-концертның иң җылы, матур мизгеле милләтебезнең легендар җырчысы, Татарстанның халык артисты Флюра Сөләйманованың сәхнәгә чыгуы булды.

– Мин Ваһапов чоры җырчыларыннан ялгызым гына калып барам кебек. Рәшит абый халык арасында искиткеч популяр кеше булды. Пластинкалар заманы иде – халык аларны бик күп алды. Рәшит абыйның үлем хәбәрен гастрольләрдә вакытта ишеттем. Ул чакта Усман Әлмиев төркемендә эшли идем, – диде Флюра Сөләйманова.

Алып баручылар соравы буенча ул «Әниемә» һәм «Алтын көмеш» халык җырларын башкаргач, залдагы тамашачылар бөек җырчыбызны аягүрә басып алкышлады.

Гала-концертта Флюра Сөләймановадан тыш тагын башка легендар җырчылар – фестиваль конкурсының жюри рәисе Ренат Ибраһимов, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Венера Ганиева, Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган артисты Илһам Вәлиев чыгыш ясады. Шулай ук фестивальнең узган еллардагы лауреатлары Азат Абитов, Гөлсирин Абдуллина, Артур Исламов чыгышларын да тамашачы бик җылы кабул итте.

Зөлфирә Шәйдуллина, Артур Салихов, Марат Яруллин, Илгиз Мөхетдинов кебек яшь егет-кызлар янәшәсендә татар тамашачысына таныш исемнәр дә шактый иде. Мәсәлән, фестивальнең иң яшь катнашучысы, Беренче каналдагы «Голос» проекты финалисты, Казанның 16нчы татар-рус гимназиясендә укучы Сәйдә Мөхәммәтҗанова, яшь җырчы Айсылу Габдинова һәм Башкортстанда яшәп иҗат итүче артист Лилиана Ирназарова, «Үзгәреш җиле» проектында катнашкан Илнар Миранов – әнә шундыйлардан.

Фестивальне оештыручыларны һәм җырчыларны Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова сәламләде.

– 2004 елда Кәрим Тинчурин исемендәге театрда беренче фестиваль ачылган иде. Ул вакытларда аның киләчәгенә кагылышлы төрле сораулар да булды. Әмма унөч ел узып та киткән. Шушы вакыт эчендә фестиваль күпме юллар, илләр, төбәкләр узып, никадәр талантлар ачылып, күпме җырчылар үстереп, эстрадага ишекләр ачып, зур эшләр эшләде, – диде ул һәм оештыручыларга рәхмәтен җиткерде.

Римма Ратникова Татарстан җитәкчеләренең Рәшит Ваһапов исемендәге фестивальгә рухи һәм матди яктан ярдәм күрсәтүләре турында да әйтеп узды һәм Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның сәламнәрен җиткерде.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

«Тәүлек буе эшләргә әзер»

Артист тамашачыны образлары аша үзенең ихласлыгына ышандырырга тиеш. Татарстанның халык артисты Илгизәр Хәсәнов әнә шундыйлардан. Ул һәр образының нечкәлеген тоя белә.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

«Әллә язмыш, әллә ялгыш» спектаклендә – Әмир Якупович, «Гайфи бабай, өйлән давай!»да – Саттар, «Төн яна учакта»да – Шакир, «Ефәк баулы былбыл кош»та – Әдһәм, «Эх, алмагачлары!»нда – Хәйбуш һ.б. образларга җан өргән артист ул. «Бибинур» фильмында Уполномоченный булып уйнады. Ул образларының эчке дөньясын ачып бирә. Аның һәр роле тормышчан. Илгизәрнең тискәре рольләре дә нәфрәт уятмый. Артист аларның да уңай якларын таба белә. Драмада да, комедиядә күбесенчә икенче пландагы ирләр ролендә уйнарга туры килде аңа. Хыялсыз кеше – канатсыз кош дигәндәй, артистның әле күңел түрендә йөрткән, уйнарга хыялланган рольләре дә бардыр. Шушы көннәрдә ул үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. 37 ел гомерен Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрына багышлаган Илгизәр Хәсәнов бүгенге көндә үзе өлкәннәр сафында.

– Гомер узган саен, рольләргә җаваплырак карыйсың, әйбәтрәк итеп уйныйсы килә. Ә инде уйналган кадәреннән канәгать булып яшисең. Авырганда, югары температура белән дә сәхнәгә чыккан чаклар була, – ди артист.

Аның турында хезмәттәшләре дә ихтирам белән сөйли.



Исламия Мәхмүтова, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты:

– Илгизәр студент чагыннан бирле театрда. Ул бик итагатьле, намуслы кеше. Үзенең ролен җиренә җиткереп эшли. Шаянлыгы белән дә аерылып тора. Аның педагоглык сәләте дә бар. Мәктәптә театр серләренә өйрәтә.

Люция Галләмова, Татарстанның атказанган артисты:

– Артист кешедә 10 процент талант булса, 90 проценты – тырышлык, диләр. Илгизәрдә талант та, тырышлык та бар. Без аның белән театр училищесында бергә укыдык. Театрга мәхәббәте көчле булгангадыр, һәрвакыт тырыш булды. Ул рольләрне бик тиз ятлый. Тимер Зиннуров безнең арадан киткәч, өч көн эчендә аның ролен ятларга өлгерде. Ул хезмәттәшләрен бик хөрмәт итә.

Нуретдин Нәҗмиев, Татарстанның халык артисты:

– Илгизәр беренче мәртәбә сәхнәдә Хыянәтче ролендә минем улым булып уйнады. Аннан соң да партнерлар булырга туры килде. Режиссер роль бирсә, тәүлек буе эшләргә әзер. Ул кешелекле дә, ышанычлы да. Аның белән разведкага барырга була.

Зөлфия Вәлиева, Татарстанның атказанган артисты:

– Ул шундый нечкә күңелле кеше. Аның эчке сиземләве көчле. Партнерына карата бик игътибарлы. Без аның белән «Төн яна учакта» спектаклендә бергә уйнадык. Ролен камилләштерү өчен, һәрвакыт партнеры белән киңәшләшеп тора. Илгизәр абый рәсемнәр ясарга да бик оста. Табигать күренешләрен бик матур сурәтли. Чиста, саф күңелле булганга, аны хатын-кызларыбыз бик хөрмәт итә.

Зөфәр Харисов, Татарстанның халык артисты:

– Илгизәр белән безнең студент елларындагы дуслык бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Ул эчкерсез, риясыз дус. Гаиләләребез белән дә аралашып яшибез. Бакчасында да ул рәссам күзлегеннән карап эш итә. Әйбәт гаилә башлыгы. Үз эшенә килгәндә, бик таләпчән, театрга баш-аягы белән кереп чумган артист.

Өммәтне алга әйдәүчеләрнең хаклары

ЖОМГА ВӘГАЗЕ

→ Ахыры. Башы 12 май санында

Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,
Түбән Кама җәмигъ мәчете имам хатибы

Никахтан соң яшь хатын иренә бер көн тәмле ризык пешерә, бер ай… Ире: «Рәхмәт яугыры, матурым, синнән дә яхшы хатын юктыр», – дип шатлана. Ләкин тора-бара ул моңа күнегә, рәхмәт хисләре юкка чыга. Ашарга әзерләүне хатынының бурычы дип саный башлый: «Пешерсен, аның эше шул!» Шуның шикелле, иренең дә еллар дәвамында гаиләсен туйдыруы, акча алып кайтуы – аның изгелеге түгел, ә коры бурычына әйләнә. «Алып кайтмый карасын!» Ә бит Аллаһы да безгә бурычлар йөкли: көн саен биш вакыт намаз уку, ураза, хаҗ һ.б. Шул ук вакытта, кылган һәр эшебезне уннан алып 700гә кадәр арттырып, рәхмәте белән, гамәл дәфтәрен тутыручы фәрештәләргә яздырта. Бер кимчелек кылсаң, аны гаделлек белән бер гөнаһ итеп язарга боера.

Пәйгамбәребез: «Әгәр сезгә бер кеше игелек кылса, аңа тиешенчә түләгез. Әгәр түләрлек нәрсә таба алмасагыз, «җитәрлек дәрәҗәдә түләдем» дип белгәнче, аның өчен изге дога кылыгыз», – дигән (Имам Әхмәт, Әбү Даут риваятьләре).

Ни өчендер бездә шул тәрбиялелек юк. Берәү, эшләгәне өчен, вакытында хакын ала, әмма рәхмәте юк. Әгәр дә хакы вакытында бирелмәсә яки азрак булып тоелса, шунда ук тәнкыйть, шунда ук гайбәт китә. Еш кына, хезмәтебезне кадерләп бетермәсәләр, гаделлек эзләргә тотынабыз, Коръәннән аятьләр дә, Пәйгамбәрнең хәдисләрен дә китерәбез. Ә эш бирүче без башкарган эшнең сыйфатын тәнкыйтьләсә, ишетергә дә теләмибез. Әлбәттә, гаеп атта да, тәртәдә дә була, эш бирүче байларның да намуссызлыгы күп гөнаһларга этәрә. Кызганыч, эшкә яллаучы белән ялланучы арасында, гаделлек җитмәү сәбәпле, җылы хисләр аз күренә. Элек татар авылында байлар һәм аларга ялланган хезмәтчеләр булган. Шулай бер көн күп еллар байга ялланып көн күргән бер ярлы, эштән тәмам арып, Аллаһыдан байлык сорап, дога кылырга уйлаган. Тәһарәтен алып, намазын укып, кулларын күтәргән дә җөмләсен тегеләй дә, болай да төзеп карамакчы булган, әмма булдыра алмаган, чөнки аның беркайчан да байлык сораганы булмаган. Шуннан ярлы: «Әй Раббым, баеган хуҗам баесын, миңа да эш бетмәсә иде», – дигән.

КАДЕР-ХӨРМӘТ КҮРСӘТҮ

Милләтенә хезмәт итүче кешеләргә кадер-хөрмәт күрсәтү зарур. Бервакыт Пәйгамбәребез янына Җәрир ибн Габдуллаһ исемле кеше керә. Ул утырырга урын таба алмагач, Пәйгамбәребез аның каршына килгән һәм чапанын җәеп, шуңа утырырга тәкъдим иткән. Җәрир чапанны җирдән алып, Пәйгамбәргә биргән һәм: «Әй Аллаһының илчесе, мине ничек хөрмәтләсәң, Аллаһы да сине хөрмәтләсен», – дигән. Пәйгамбәребез: «Әгәр сезгә бер халыкның хөрмәтле кешесе килсә, сез дә аны хөрмәтләгез», – дигән (Табәрани риваяте).

Пәйгамбәребез төрле халыкларның патшаларын иманга чакырып хатлар язганда, аларга ихтирам белән мөрәҗәгать иткән. «Аллаһының илчесе Мөхәммәт ибн Габдулладан – Румның бөек патшасы Һираклийга…», «Кыйптыйларның бөек патшасы Мокаукыйска…», «Фарсыларның бөек патшасы Хөсрәүгә…» һ.б. Хикмәтле Пәйгамбәр әлеге патшаларга хатларны тапшыручы өчен күркәм кыяфәтле, зирәк акыллы, җирле телне һәм гадәтләрне белгән иң лаеклы кешеләрне сайлаган.

Сөекле Пәйгамбәребез иң авыр вакытларында үзенә тугры булган сәхабәләрен ничек зурлый?! Әгәр пәйгамбәрлек чоры 23 ел булса, шуның беренче өч елында Пәйгамбәребез яшерен дәгъват алып бара, үзен пәйгамбәр итеп игълан кылмый. Ул кораешләр арасыннан иң гаделе, иң хәерле кешеләрне сайлап, гомум халыкка чәчелмичә, бөтен көчен аерым шәхесләрне тәрбияләүгә юнәлтә. Нәтиҗәдә, аның хатыны Хәдичә, анары кызлары динне кабул итә. Яшьләрдән, беренче булып, Гали иман китерә, ә ирләрдән Әбү Бәкер иярә. Пәйгамбәребез үзенә иярүче сәхабәләрен дин рухында тәрбияләү өчен, мәдрәсә буларак, Аркам ибн Әбү Аркамның йортын сайлый. Әлеге мәдрәсә диварлары артында иман нурын җирнең офык-кырларына таратырдай ирләр тәрбияләнеп чыга. Соңрак, чыннан да, алар аша күпме кеше иманга килеп, кабиләләрнең, шәһәр һәм илләрнең җитәкчиләр. Сөекле Пәйгамбәребез әүвәлгеләрне һәрвакыт ярата, аларның кадерләрен белә.

Кадерле Хәдичәсе беренче көннән башлап соңгы сулышына кадәр иренә таяныч, терәк була. Аллаһының илчесе, җаны сызланган вакытларда, нәкъ аның янәшәсендә күңеленә тынычлык таба. Хәдичә исән булганда да Пәйгамбәребез хисләрен яшерми, аны җирләгәч тә, аңа булган кадер-хөрмәтен гел искә ала. Гайшә әйтүенчә: «Хәдичәдән көнләшкән кебек, Пәйгамбәребез хатыннарының берсеннән дә көнләшмәдем, гәрчә аны күргәнем булмаса да. Ул аны гел искә ала иде. Еш кына, сарык суйгач, аның бер өлешен кисеп, Хәдичәнең якыннарына җибәрде. Кайвакыт мин аңа: «Бу дөньяда Хәдичәдән башка хатын-кызлар юктыр инде», – дип тә әйтә идем. Ул: «Хәдичәм шундый, шундый иде. Ул миңа балалар тудырды», – дип сөйли иде» (Бохари җыентыгыннан).

Әбү Бәкер Сыйддикъ. Пәйгамбәребезгә һәрвакыт тугры булып калганы өчен Сыйддикъ, ягъни «тугры» исемен ала. Пәйгамбәребез аны ничек ярата, ничек яклый?! Сөекле Пәйгамбәребез сәхабәләренә үзенең тиздән Раббысы янына күчәсен белдергәч, Әбү Бәкер елый башлый. Пәйгамбәр, аны юатып: «Әбү Бәкер, елама. Бар кешеләр арасыннан миңа үзенең дуслыгы һәм малы белән иң тугры булган кеше – Әбү Бәкер. Әгәр өммәтемнән бер кешене иң якын дустым итеп сайларга кирәк булса, мин Әбү Бәкерне сайлар идем», –ди (Бохари риваяте). Гомәр ибн Хаттаб: «Әбү Бәкер – безнең әфәндебез, арадан иң хәерлебез, Аллаһының илчесенә иң сөекле булганыбыз»,– ди (Тирмизи риваяте).

Госман ибн Гаффән. Пәйгамбәребез Госманны ярату гына түгел, ул аннан ояла да. Гайшә тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез: «Ничек мин фәрештәләр дә оялган кешедән оялмыйм инде?!» ди (Мөслим риваяте). Табүк сугышы алдыннан, гаскәрне әзерләү өчен, Пәйгамбәребез сәхабәләрдән ярдәм сорый. Шулвакыт Госман 940 дөясен, 60 атын сәдака итеп бирә. Өстәвенә мең динар акча китереп, Пәйгамбәрнең каршына коя. Пәйгамбәр, аларны җыеп: «Бу көннән соң Госманга һичнәрсә зарар китермәс», – дип ике мәртәбә кабатлый. Шулай итеп, Аллаһы илчесе аны барча кеше алдында зурлый, мактый һәм тагы да изге эшләр кылу өчен, гайрәтен күтәрә. «Йә Аллаһы, Госманнан риза бул, мин аннан риза», – дип, изге догасын кыла (Ибн Һишәмнән килә).

Пәйгамбәребез яраткан кызы Рукаяны Госманга кияүгә бирә. Рукая вафат булгач, аңа икенче кызы Өммегөлсемне бирә. Өммегөлсем дә Раббысы хозурына күчкәч, кайгыга чумган киявен юатырга тырышып: «Әгәр безнең өченче кызыбыз булса, анысын да сиңа бирер идек», – ди.

Яраткан сәхабәсе Гали ибн Әбү Талибка Пәйгамбәребез яраткан кызы Фатыйманы бирә. Галинең Фатыйма өчен мәһәргә бирерлек малы да булмый. Пәйгамбәр, аның иске көбәсен сорап, кызын никахлаштыра. Бервакыт Фатыйма янәшәсендә Галине күрмәгәч: «Гали кайда?» – дип сорый. Фатыйма: «Без аның белән бераз әрләшкән идек, ул чыгып китте әле», – ди. Пәйгамбәребез аны эзләргә тотына һәм мәчеттә йоклап ятканын күрә. Галинең чапаны өстеннән төшеп, аның өсте тузан белән капланган була. Пәйгамбәр, Галинең тузаны кагып: «Тор, Әбү Турап, тор, Әбү Турап (тузан атасы)», – дип аны уята (Бохари һәм Мөслим риваятьләре). Соңрак Галинең үзе иң яраткан кушаматы да Әбү Турап була.

ЯРДӘМ ИТҮ

Әлбәттә, әллә нинди көч-куәт ияләренең дә зәгыйфь яклары була. Берәүнең сәламәтлеге какшый, кемнеңдер гаиләсендә тәртип булмый, кемгәдер җан тынычлыгы җитми. Шуңа күрә без андыйларга – кирәк булса, көчебез, малыбыз, ихлас киңәшебез белән ярдәм итәргә бурычлы. Кечкенә Һөдһөд кошы бөек патша Сөләйман янына кайтып, аңа Сәбәгъ патшабикәсенең кояшка табынып яшәвен сөйли һәм ул халыкның хак дингә килүенә сәбәп була.

Кайвакыт, көч-куәт ияләренең хәзинәдәге маялары бетеп, алар үзләре матди ярдәмгә мохтаҗ була. Пәйгамбәребез: «Дин ул – нәсыйхәт (ихласлык, тугрылык)», – ди. Кешеләр: «Кемгә?»– дип сорыйлар. Пәйгамбәр: «Аллаһыга, Китабына, илчесенә, мөселманнарның имамнарына һәм гомум кешеләренә»,– ди (Мөслим риваяте).

Шулай бервакыт шактый күп хәйрия эшләре алып барган кардәш шалтыратты һәм: «Бу дөнья дигәне кызык икән, хәзрәт. Гомер буе бөтен кешегә гел биреп яшәргә тырыштым, кешедән сорамадым. Хәзер үземә әҗәткә акча кирәк булды, кемнән генә сорасам да, бирмәделәр»,– ди. Шулай, дөнья кешегә бер алдын куйса, бер артын да куя…

Шөкер, бүген дөнья безгә үз капкаларын киң итеп ачты. Без генә, күптән ризык күрмәгән ач кешеләрдәй, шуңа ташландык. Безне барысы да кызыктыра, бөтенесен тизрәк кабып, тотып, татып, киеп карыйсы, барып күрәсе килә. Бер нигъмәтне кулга алганда, күз икенчесенә төшә. Мәңге туймас нәфесне туендыру шөгыленнән кайчан чыгарбыз да Аллаһы биргән көчләребезне чыннан да изге булган эшләргә кайчан юнәлтә башларбыз икән? Милләтебезнең Фәхреддиннәре, Хөсәеновлары тагын кайчан булыр икән?

Йа Раббым, гасырлар дәверендә милләтебезнең иманы, хәерле тормышы өчен янып-көеп яшәгән кардәшләребездән Үзең разый бул. Исән булганнарына – бәрәкәтле тормыш, киң ризык, тән саулыгы, җан тынычлыгы, хәләл маллар, тәүфыйк-һидаят бир. Мәңгелек сәфәргә юл тотучыларның хаталарын кичереп, каберләрен оҗмах бакчасының бер бакчасы итсәң иде. Үзебезне дә, бала-оныкларыбызны да файдалы бәндәләр итсәң иде. «Ни Аллага, ни бәндәгә» булып, башкалар өчен хәсрәт китереп яшәүләрдән сакласаң иде.

Андрей Кузьмин:

«Татар-информ» Татарстанда беренче ресурска әверелергә тиеш

Журналистларның һөнәри бәйрәме – 19 майда билгеләп үтелә торган Татарстан матбугаты көне алдыннан «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Андрей Кузьмин республиканың әйдәп баручы мәгълүмат агентлыгы алдына куелган яңа бурычлар хакында сөйләде.

Наталья РЫБАКОВА

27 ел эшләү дәверендә беренче тапкыр «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының уникаль кулланучылар саны аена 1 миллионнан артып китте. Тематик яктан телгә алыну индексы буенча агентлык Татарстанда – беренче, Идел буенда өченче урынны били. Мондый уңышка «Татмедиа» АҖ структурасында үткәрелгән зур үзгәрешләр нәтиҗәсендә ирешелде.

– Андрей Владимирович, «Татар-информ» коллективы үзенең һөнәри бәйрәмен нинди нәтиҗәләр белән каршылый?

– Теләсә кайсы басма – газета, журнал, телекомпаниянең үз үсеш этаплары бар. «Татар-информ»да тамырдан үзгәреш монннан бер ел элек башланды дип уйлыйм. Агентлыкка Шамил Садыйков җитәкчелегендә яңа команда килде. Коллектив алдына яңа бурычлар куелды. Аларны гамәлгә ашыру өчен билгеле бер адымнар ясалды. Боларның барысы да «Татар-информ» Татарстанның төп мәгълүмат агентлыгына әверелсен өчен эшләнде. «Татар-информ» – дәүләт структурасы ул, безнең бурыч – республика һәм дөнья халкына Татарстанда бара торган вакыйгалар турында мәгълүмат бирү. Дәүләт сәясәтен аңлату, Президент, Хөкүмәт, Дәүләт Советы эше турында сөйләү. Моны аңлаешлы, оператив төстә эшләргә кирәк. Теләсә кайсы интернет-басманың бәяләү критерие – кулланучыларның саны. Матбугат көне алдыннан без бурычның беренче этабы үтәлде дип әйтә алабыз. «Татар-информ»ның уникаль кулланучылар саны аена 1 миллионнан артып китте.

– «Татмедиа»дагы үзгәрешләр хакында сөйләгез әле. Нәрсәләр эшләнде?

– «Татмедиа»да берничә мәгълүмати ресурс эшли иде, аларны берләштерү турында карар кабул ителде. Бүгенге көндә «Татар-информ» берничә мәгълүмати ресурсны (рус һәм татар телендәге мәгълүмат агентлыгы, sntat.ru һәм Intertat.ru порталлары, «События недели» һәм «Атна вакыйгалары» газеталары) үз эченә ала. Бүген ул, минемчә, республика һәм Идел буенда иң заманча яңалыклар фабрикасы.

– Социаль челтәрләр белән эш ни рәвешле оештырылган?

– «Татмедиа»да «Татар-информ» яңалыкларын тарату белән шөгыльләнә торган социаль медиа бүлеге оештырылды. Хәзер күпләр сайтка социаль челтәрләр аша керә. Әгәр бер ел элек сайтка социаль челтәрләрдән аена 15,5 мең кеше керсә, хәзер ул 14 мәртәбә диярлек артып, 208 меңгә җитте.

– Татар редакциясен үстерү хакында нәрсә әйтә аласыз?

– Без татар сегментын үстерүгә җитди игътибар бирдек. Татар редакциясе сизелерлек киңәйтелде. Агентлыкка Рәмис Латыйпов җитәкчелегендә яңа команда килде. Бер ел эчендә коллектив зур ыргылыш ясады. Татар телендә уникаль материаллар дөнья күрде. Бер ел эчендә, 2016 елның маеннан 2017 елның маена кадәр, сайтның татар версиясе уникаль кулланучылар санын уртача 7,5 тапкыр арттырды. Бүген ул республикада һәм аннан читтә иң күп укыла торган интернет-ресурсларның берсенә әверелде. Татар телле интернетның мәгълүмат сегментында бу – беренче урында торучы коллектив. Шушы ук команда татар телендә газета да чыгара.

– Агентлыкның төп миссиясе нидән гыйбарәт?

– Россия һәм бөтен дөньяда Татарстан турында беренче урындагы мәгълүмати ресурска әверелү.

Реклама

Быел күренекле дин белгече, мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, педагог Галимҗан Баруди тууына – 160 ел. Шул уңайдан Казан федераль университетының Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе (ИТИС) белән Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институты татар теле һәм әдәбияты буенча «Баруди» дип аталган Бөтендөнья онлайн контроль эше үткәрә. Теләгән һәр кеше үз белемнәрен 26 май көнне сынап карый ала.

«Баруди» контроль эше: татарча, заманча, үзгә

Узган ел студентлар шундый ук чараны Габдулла Тукайның 130 еллыгына багышлап үткәргән иде. Анда бөтендөнья буйлап 10 мең кеше катнашты. Быелгы биремнәр дә үзенчәлекле.

– Узган елны контроль эше чит илләрдә яшәүче татарлар арасында да зур кызыксыну уяткан иде. Япониядән Мизуки, Юто исемле кыз белән егет катнашты. Алар әле дөньякүләм татар теле олимпиадасы җиңүчеләре дә. Быел да проектта бик теләп катнашачаклар. АКШ, Европаның төрле илләренә күчеп киткән татарлар да контроль эшкә битараф калмады. Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстаннан да катнашучылар бар иде, – ди онлайн контроль эше оештыручыларының берсе Азат Кашапов.

Контроль эш ике этаптан тора. Беренче тестта татар телен белү дәрәҗәсе сынала. Икенчесендә Галимҗан Баруди шәхесенә кагылышлы сораулар булачак. Аларга бер сәгать эчендә җавап бирергә кирәк. Ике этапны да уңышлы узган кешеләргә гаҗәп кызыклы фактлар белән тулыландырылган «Галимҗан Баруди тормыш картасы» тапшырыла.

– Быелгы биремнәр катлаулырак булачак. Тукай тормышын һәм иҗатын күп кеше белә, ә менә Галимҗан Баруди турында, кызганыч, белүчеләр азрак. Тестны уңышлы үтү өчен, Баруди тормышын юлын яхшы белергә кирәк. Татар теле кагыйдәләре, төрле әйтемнәре, мәкаләләре турында да сораулар күп. Контроль эшенә кадәр алдан «таныш тестын» үтеп була. Tattest.ru дигән рәсми сайтыбыз инде ачык, – ди Азат.

Онлайн контроль эшендә катнашу өчен, шул сайтта алдан ук теркәлергә кирәк. Аның нәтиҗәсендә һәр катнашучыга онлайн сертификат бирелә.

Контроль эш 26 май көнне төнге 12дә башланып, 27 май төнге 12дә тәмамлана. Әлеге вакыт башка сәгать поясында урнашкан чит ил катнашучылары өчен дә уңайлы булсын дип сайланган.

Алисә САБИРОВА.

Китапханә – паркта

27 майда – Гомуроссия китапханәләр көнендә – Татарстан Республикасы Милли китапханәсе «Китапханә паркта» дигән мәдәни-мәгърифәти чара уздыра. Бәйрәм чарасы Казан шәһәренең «Черек күл» паркында сәгать 11дән көндезгә 3кә кадәр үткәреләчәк.

Бәйрәм программасына театраль корылышка нигезләнгән күргәзмәле тематик мәйданчыклар эше кертелгән. Паркка килгән һәрбер кеше иң кызыклы һәм мөһим китаплар, әдәби әсәрләр белән танышып кына калмый, режиссерлар уйлап тапкан һәм тәкъдим иткән интерактив уен-күренешләрдә катнаша, үзе яраткан әсәрләрдән өзекләр укый, музыка коралларында уйный, рәсем ясап карый алачак.

Бәйрәмнең башыннан ахырына кадәр балалар өчен уен мәйданчыгы эшләячәк. Анда әдәби әсәрләр каһарманнары чыгыш ясар, балалар үзләре дә, битләрен буяп, танылган персонажларга әверелер, һәртөрле ярыш-бәйгеләрдә, отыш лотереясында, китапханә эше осталарының һәм курчак театрының мастер-классларында катнашыр, онытылмаслык әкияти сынаулар аша узар, гаҗәпләндерә торган тематик «Фәнни шоу» һәм башка кызыклы, күңелле һәм мавыктыргыч тамашалар күрер дип көтелә.

Үзәк мәйданчыкта чараның иң күңелле өлеше – Казан дәүләт мәдәният институтыннан килгән сәнгать төркемнәре һәм сәләтле башкаручылар катнашындагы театральләштерелгән концерт булачак.

«Ачык микрофон» кысаларында, республикабыз язучылары һәм шагыйрьләре, төбәгебездә чыгып килә торган вакытлы матбугат басмалары вәкилләре, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре чыгыш ясаячак.

Шулай ук Татарстанның иҗат дөньясындагы күренекле шәхесләр белән очрашулар, китап күргәзмәләре һәм иллюстратив тематик күргәзмәләр, нәшрият эшчәнлегенә караган остаханә оештырылачак.

Китапханәчеләр иҗатына багышланган күргәзмә-ярминкәдә истәлеккә яки бүләк итү өчен кул эшләнмәләре, сувенирлар сатылачак. Буккроссинг яратучылар өчен китаплар алмашу, ягъни укылган китапны киштәдә калдырып, үзеңә ошаган башка китапны алу мөмкинлеге тудырыла. Шулай ук барлык теләүчеләр өчен «Ачык һавадагы уку залы» эшләячәк, китапханәгә беренче тапкыр мөрәҗәгать итүчеләргә бердәм укучы билеты бирү дә каралган.

Бу чара җәмәгатьчелекнең игътибарын китап укуга юнәлтү, китапның иҗтимагый һәм мәдәни тормыштагы әһәмиятен арттыру, халыкны китапханәләргә җәлеп итү максаты белән уздырыла. Бәйрәмнең шигаре – «Укы. Уйла. Сөйлә. – Читай. Думай. Говори. – Read. Think. Speak». Рәхим итегез!

БЕЛМИ КАЛМА

«КАРАВОН» кызык булачак. Кил!

Лаеш районының Никольское авылында уза торган «Каравон» рус фольклор фестиваленең программасы быел тагын да баерак булачак дип вәгъдә итә оештыручылар.

XXV Бөтенроссия фольклор фестивале 20 май көнне үк кичке уеннар белән башланып китәчәк. Ә 21 майда узачак фестивальдә катнашырга барлыгы 158 коллектив теләк белдергән. Липецк шәһәренең легендар «Казаки России» бию театрының чыгышларын күрер өчен генә дә барырлык быелгы «Каравон»га. Моның өстенә, Россиянең 15 шәһәреннән 320гә якын кулланма-гамәли сәнгать осталары, һөнәрчеләр килүе дә көтелә. Димәк ки, алар уздырган осталык дәресләрендә катнашу, төрле эшләнмәләрне останың үз кулыннан алу мөмкинлеге дә булачак дигән сүз.

Соңгы өч ел тәҗрибәсе күрсәткәнчә, «Каравон» фестивалендә 20-25 мең кунак килә, диләр оештыручылар. Биредә орчык буе балалар да, аларның әти-әниләре дә күңеленә хуш килгән мәйданны сайлый алачак. Төп тамаша Россиянең, Татарстанның фольклор коллективлары катнашында «Разгуляй!» концерт мәйданында барыр дип көтелә. «Каравон тарихы» музее да күпләрдә кызыксыну уятачак. Һөнәрчеләрнең ишегаллары да шактый бай булырга охшый. «Халык модасы» мәйданында исә рус милли киемнәре күрсәтеләчәк. Моннан тыш тамашачыларны театр, бию, гаилә квестлары һ.б. мәйданчыклар көтә. Быел беренче тапкыр балалар мәйданчыгы эшләячәк. Анда балалар фольклор төркемнәренә йөрүчеләр уеннар оештырачак.

Казаннан фестивальгә баручылар өчен 21 май көнне иртәнге 8.00-9.00 арасында «Җиңү Проспекты», «Корстон», Камал театры тукталышлары янынннан бушлай автобуслар кузгалачак. Никольскидан Казанга кайтучылар өчен дә автобуслар каралган. Бәйрәмгә шулай ук 65 сум билет бәясе түләп, «Южный» автовокзалыннан кузгала торган 118нче маршрут автобусы белән дә барып була (автобус Казаннан 8.00, 14.20, 17.10да кузгала, ә Никольскидан – 9.30, 15.55 һәм 18.30 сәгатьләрдә). Үз транспортында баручыларга да аптырап йөрисе юк, биш җирдә парковка булачак. Медицина ярдәме кирәк булган очракта, махсус билгеләнгән «Ашыгыч ярдәм» бригадаларына мөрәҗәгать итәргә мөмкин булачак.

Расиха ФӘИЗОВА.

«Әкият»ләләр «Кунак сарае»на бара

«Әкият» Татар дәүләт курчак театры 18-21 майда Оренбургта «Кунак сарае» IX Халыкара курчак театрлары фестивалендә катнашачак.

Труппа жюри һәм тамашачылар хөкеменә Цагарелиның «Ханума» спектаклен тәкъдим итәчәк. Аның премьерасы 2015 елда булган иде. Сәхнәгә аны Россия һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер Илдус Зиннуров куйды. Рәссамы – «Алтын битлек» илкүләм театраль премия лауреаты Захар Давыдов. Фестивальгә чакыру алганчы, «Әкият» театры сайлап алу турларын узды.

– Безнең өчен бу бик шатлыклы вакыйга. Дөньяның башка коллективлары белән көч сынашачакбыз, аларның актерлары, режиссерлары белән тәҗрибә уртаклашачакбыз, – ди театрның директоры Роза Җаббарова.

Фестивальдә Израил, Мәскәү, Пермь, Ереван, Магнитогорск, Омск һәм башка төбәкләрдән театр коллективлары катнашачак.

Иң яхшы биючеләр – Казанда

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында 13 майдан 30ына кадәр XXX Халыкара классик балет фестивале уза. Тамашаче хозурына тугыз спектакль, ике йомгаклау концерты тәкъдим ителә.

Фестиваль «Ромео и Джульетта» спектакле белән ачылды. «Дон Кихот», «Лебединое озеро», «Жизель» кебек балетлар белән бергә, Резеда Ахиярованың «Алтын Урда»сы да күрсәтеләчәк. Болгария, Германия, Норвегия, Испания кебек илләрдән һәм Россия шәһәрләреннән 30дан артык биюче килүе көтелә. Алар арасында Норвегия милли балетыннан илнең иң оста биючесе Осиэль Гунео да бар. Ул «Дон Кихот» балетында бии.

Фестивальдә шулай ук «Лебединое озеро», «Баядерка», «Анюта», «Жизель» кебек балетлар күрсәтеләчәк. Үзебезнең артистлардан тыш Америка, Германия, Белоруссия, Бөекбритания кебек илләрдән 30 балет биючесе килер дип көтелә. Мактаулы кунак булып СССРның халык артисты Владимир Васильев киләчәк.

Әлеге чара Президент Рөстәм Миңнеханов һәм Мәдәният министрлыгы ярдәме белән оештырыла.

Не копайте где попало!

УВАЖАЕМЫЕ ГРАЖДАНЕ!
В ПОСЛЕДНЕЕ ВРЕМЯ УЧАСТИЛИСЬ СЛУЧАИ НЕСАНКЦИОНИРОВАННОГО ПРОИЗВОДСТВА ЗЕМЛЯНЫХ РАБОТ В ОХРАННЫХ ЗОНАХ ГАЗОРАСПРЕДЕЛИТЕЛЬНЫХ СЕТЕЙ. ПРИ ЭТОМ ВОЗНИКАЕТ ОПАСНОСТЬ МЕХАНИЧЕСКОГО ПОВРЕЖДЕНИЯ ИНЖЕНЕРНЫХ СООРУЖЕНИЙ, ТРАНСПОРТИРУЮЩИХ «ГОЛУБОЕ ТОПЛИВО».

18.02.16г. в Черемшанском р-не, н.п.Верхняя Кармалка при проведении земляных работ по прокладке сборного нефтепровода, экскаватором был поврежден межпоселковый подземный газопровод высокого давления, в результате чего были временно отключены от газоснабжения 84 жилых дома и 2 коммунально-бытовых объекта.

28.04.16г. в Арском р-не, н.п.Старое Чурилино при проведении физическим лицом земляных работ по установке столба, был поврежден межпоселковый подземный газопровод высокого давления, в результате чего были временно отключены от газоснабжения 44 жилых дома.

30.04.16г. в Советском р-не, поселок «Союз офицеров и прапорщиков» при проведении физическим лицом земляных работ по прокладке водопровода, был поврежден подземный газопровод среднего давления, в результате чего были временно отключены от газоснабжения 300 жилых дома.

31.05.16г. в Высокогорском р-не, н.п.Большой Битаман при проведении земляных работ ООО «Таттелеком» был деформирован подземный полиэтиленовый газопровод среднего давления, в результате чего были временно отключены от газоснабжения 172 жилых частных дома.

03.05.17г. в Елабужском р-не, н.п.Мальцево при проведении земляных работ частным лицом был поврежден подземный полиэтиленовый газопровод среднего давления, в результате чего были временно отключены от газоснабжения 123 жилых дома и 2 коммунально-бытовых объекта.

Все работы проводились самовольно, без оформления разрешительных документов и вызова на место проведения работ представителей эксплуатационной организации. Во всех случаях затраты на восстановление газоснабжения были взысканы с виновных лиц.

Перебои в газоснабжении потребителей – это лишь одно из возможных и относительно безобидных последствий данных действий. Гораздо страшнее, когда по причине нарушения работы газопровода происходит утечка газа, взрыв, пожар, разрушение зданий – все это может привести к массовым человеческим жертвам.

ООО «ГАЗПРОМ ТРАНСГАЗ КАЗАНЬ» НАПОМИНАЕТ, что согласно «Правил охраны газораспределительных сетей», утвержденных Постановлением Правительства РФ №878 от 20 ноября 2000 года, для газораспределительных сетей устанавливаются охранные зоны:

- вдоль трасс подземных газопроводов – в виде территории, ограниченной условными линиями, проходящими на расстоянии 2 метров с каждой стороны газопровода;
- вокруг отдельно стоящих газорегуляторных пунктов – в виде территории, ограниченной замкнутой линией, проведенной на расстоянии 10 метров от границ этих объектов;
- вдоль трасс межпоселковых газопроводов, проходящих по лесам – в виде просек шириной 6 метров, по 3 метра с каждой стороны газопровода. Для надземных участков газопроводов расстояние от деревьев до трубопровода должно быть не менее высоты деревьев.

Трассы подземных газопроводов обозначаются опознавательными знаками желтого цвета, нанесенными на постоянные ориентиры или железобетонные столбики высотой 1,5 метров. На опознавательных знаках наносится надпись «ГАЗ», эксплуатационная информация и телефон аварийно-диспетчерской службы.

Отсчет расстояний при определении охранных зон газопроводов производится от оси газопровода – для одониточных газопроводов и от осей крайних ниток газопроводов – для многониточных.

На земельные участки, входящие в охранные зоны газораспределительных сетей, налагаются ограничения (обременения), В частности, юридическим и физическим лицам, являющимся собственниками, владельцами или пользователями земельных участков, расположенных в пределах охранных зон газораспределительных сетей, либо проектирующим объекты жилищно-гражданского и производственного назначения, объекты инженерной, транспортной и социальной инфраструктуры, либо осуществляющим в границах указанных земельных участков любую хозяйственную деятельность, запрещается:

- строить объекты жилищно-гражданского и производственного назначения;
- перемещать, повреждать, засыпать и уничтожать опознавательные знаки, контрольно-измерительные пункты и другие устройства газораспределительных сетей;
- устраивать свалки и склады, разливать растворы кислот, солей, щелочей и других химически активных веществ;
- огораживать и перегораживать охранные зоны, препятствовать доступу персонала эксплуатационных организаций к газораспределительным сетям, проведению обслуживания и устранению повреждений газораспределительных сетей;
- разводить огонь и размещать источники огня;
- рыть погреба, копать и обрабатывать почву сельскохозяйственными и мелиоративными орудиями и механизмами на глубину более 0,3 метра;
- открывать калитки и двери газорегуляторных пунктов, станций катодной и дренажной защиты, люки подземных колодцев, включать или отключать электроснабжение средств связи, освещения и систем телемеханики;
- набрасывать, приставлять и привязывать к опорам и надземным газопроводам, ограждениям и зданиям газораспределительных сетей посторонние предметы, лестницы, влезать на них;
- самовольно подключаться к газораспределительным сетям.

Хозяйственная деятельность в охранных зонах газораспределительных сетей, не предусмотренная вышеперечисленными пунктами, при которой производится нарушение поверхности земельного участка и обработка почвы на глубину более 0,3 метра, осуществляется на основании письменного разрешения эксплуатационной организации газораспределительных сетей.

ЮРИДИЧЕСКИЕ И ФИЗИЧЕСКИЕ ЛИЦА, ВИНОВНЫЕ В НАРУШЕНИИ ТРЕБОВАНИЙ НАСТОЯЩИХ ПРАВИЛ, А ТАКЖЕ ФУНКЦИОНИРОВАНИЯ ГАЗОРАСПРЕДЕЛИТЕЛЬНЫХ СЕТЕЙ, ПРИВЛЕКАЮТСЯ К ОТВЕТСТВЕННОСТИ В ПОРЯДКЕ, УСТАНОВЛЕННОМ ЗАКОНОДАТЕЛЬСТВОМ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ.

Убытки, причиненные в результате повреждения газораспределительной сети, нарушающие бесперебойную или безопасную работу газораспределительной сети, исчисляются и взыскиваются с виновных лиц в порядке, установленном законодательством Российской Федерации.

Реклама

Җанны җылытучы итекләр

Татарстанның «Кукмара киез итек-киез комбинаты» элек-электән килгән традицияләр һәм заманча технологияләрне берләштергән продукция эшләп чыгара.



КУЛДАН ЭШЛӘНГӘН

«Кукмара» дип әйтүгә, иң беренче тел очына килгән сүз, әлбәттә инде, «итек». Кукмара итекләрен Россиянең барлык төбәкләрендә беләләр. Күпме еллар узса да, бездәге салкыннар өчен итектән дә яхшырак һәм уңайлырак аяк киеме уйлап таба алмадылар әле. Аның заманча модельләре җылы гына түгел, модалы да. Кукмара комбинатында табигый йоннан басылган итекнең яңа дизайннарын уйлап табып кына торалар.

Кукмара итекләренең чишмә башы XIX йөз ахырына – «Бертуган Комаровлар» шәхси Сәүдә йортына барып тоташа. Бертуган Комаровлар җирле халыктан йон сатып ала һәм аны фабрикага тапшыра. Биредә тетелгән йонны өйдә эшләүчеләргә тараталар. Тегеләре исә әлеге ярымфабрикаттан көненә кулдан 600 (!) пар итек баса. Бертуган Комаровларның мең ярымнан артык эшчесе булган. Шул рәвешле, Кукмара итекләренең даны еракларга тарала. «Бертуган Комаровлар» Сәүдә йорты Париж һәм Лейпциг, шулай ук Россия сәүдә ярминкәләре медальләренә лаек була.

Октябрь революциясеннән соң фабрика дәүләт карамагына күчә. Индустрияләштерү чорында предприятиедә итек басу һәм техник киез җитештерү буенча яңа корпуслар төзиләр. 1936 елда фабрикада станок һәм технологияләрне камилләштерәләр, бу – җитештерүчәнлекне сизелерлек арттырырга мөмкинлек бирә.

СУГЫШ ЕЛЛАРЫНДА ДА ЯБЫЛМЫЙ

Бөек Ватан сугышы елларында, күпчелек ир-ат хезмәткәрләр яу кырына китеп барса да, фабрика эшләвен дәвам итә – биредә фронтка 1,5 миллион пар киез итек озаталар, фронттан кайтарылган 6 миллион пар аяк киеменә реставрация ясыйлар.

Сугыштан соң предприятие икенче яшьлеген кичерә: конвейерлаштыру принциплары, Кукмара фабрикасында инженер Архипов тарафыннан булдырылган яңа алымнар кертелә. Нәтиҗәдә, фабрика Россиядә киез итек-киез җитештерү буенча әйдәп баручы предприятиеләрнең берсенә әверелә.

Революциягә кадәр һәм совет чорында итек басу Кукмара бистәсенең икътисади нигезен тәшкил итә. Шуның хисабына энергия, электр, газ белән тәэмин итү, социаль объектлар, юллар, торак йортлар төзелә.

Хәтта ил базар мөнәсәбәтләренә күчкәч тә, Кукмара фабрикасы, аягында нык басып калу белән бергә, яңарыш кичерүен дәвам итә. Предприятиедә сырган әйберләр һәм тупас йонлы киез, балалар һәм хатын-кыз аяк киемнәре эшләп чыгара башлыйлар.

Чимал белән тәэмин итү һәм әзер продукцияне сату структурасын тамырдан үзгәртеп, продукциянең сыйфатын яхшыртып, комбинат җитештерүдә үзгәртеп кору чорына кадәрге дәрәҗәгә ирешә. 2001 елдан предприятие 1 миллион пардан артык киез итек җитештерә.

ДӘВАЛАУ СӘЛӘТЕНӘ ДӘ ИЯ

Кукмара комбинатында ассортиментны даими рәвештә киңәйтәләр, эшләнмәләрнең сыйфатын һәм дизайнын яхшырталар. Биредә мех һәм күн кулланып, сәйлән белән чигелгән итекләр дә басалар, аларны шәһәр кешеләре дә яратып кия. Сатып алучысы булганга, мондый итекләрне җитештерү күләме артканнан-арта бара.

Фабрикада киез итек һәм югары сыйфатлы тула, табигый сарык йоны кушып эшләнгән сырган юрганнар, жилетлар, балалар, мунча өчен киез комплектлар белән бергә, киездән заманча, уңайлы, модалы аяк киемнәре дә (угги, оек, тапочка, чунилар, җиңсез чикмән, ботинка, күн итек һ.б.) тегәләр. Комбинатта җитештерелгән киез аяк киемнәренә тиңнәр юк. Һич югы бер генә тапкыр булса да йон тапочкалар киеп карагыз әле: алар шундый уңайлы, аякка рәхәт, хәтта саласы да килми.

Киездән эшләнгән заманча аяк киемен элеккесе белән чагыштырып та булмый: алар бик җиңел, аяклар сулый һәм суыкта өшеми.

Табигый аяк киеме һәрвакыт модада, өстәвенә ул дәвалау һәм савыктыру үзлекләренә дә ия. Шунлыктан Европа илләрендә киез итекләрне, дарулар белән бергә, аптекаларда да саталар. Татарстанда табигый материаллардан аяк һәм өс киемнәре җитештерә торган фабрика әлегәчә сакланып калган икән, без аның кадерен белергә тиеш. Аларның бәясе дә кесәгә артык сукмый. Шулай булгач, җаныгыз ни тели, шуны сайлап алыгыз.

Эчсәң эч, ләкин сатма

Кайбер кешеләрнең өй шартларында спиртлы эчемлекләр әзерләве «хәрби сер» түгел. Әмма өйдә ясалган самогонны, шәрабны һәм ачы балны сату закон нигезендә тыела.

Менделеев шәһәрендә яшәүче бер хатынны шайтаннар: «Сат-сат!» – дип котыртып тора, күрәсең. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чаллы территориаль органы хәбәр итүенчә, әлеге хатын самогон сатканда бер фаш ителгән.

Өй шартларында, сату максатында, этил спирты катнашмалы сыеклыклар әзерләсәң, Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 2.8 маддәсе нигезендә, 3 мең сумнан 5 мең сумга кадәр штраф салына, продукция конфискацияләнә. Әлеге хатын да өендәге алты литр самогонын үз ихтыярында хокук сакчыларына чыгарып биргән. Тагын штраф түләргә туры киләчәк.

Менделеев шәһәрендә соңгы ике атнада маркасы булмаган спиртлы эчемлек сатуның да ике очрагы теркәлгән. Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеев районы буенча бүлеге хезмәткәрләре Менделеев шәһәрендә яшәүче кешенең машинасыннан, ялган маркалы булуда шикләнеп, ике тартма аракы тартып алган. Икенче бер хатын күршесенә ялган маркалы аракы саткан. Тагын ике шешә «шайтан төкереген», ягъни ялган аракысын хокук сакчыларына үз ихтыярында тапшырган. Бу фактлар буенча Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 4нче бүлегенең 15.12 маддәсе нигезендә, административ эш кузгатылган. Маркасы һәм мәгълүматлары булмаган товарны саткан, саклаган яки алып барган өчен гражданнарга 2 мең сумнан 4 мең сумга кадәр штраф каралган. Җитәкчеләргә – 5 мең сумнан 10 мең сумга, ә юридик затларга 50 мең сумнан 300 мең сумга кадәр штраф түләттерелә. Моны хәтерегездән чыгармагыз, чөнки законны белмәү барыбер дә җаваплылыктан азат итми.

Дамир БӘДРИЕВ.

В 2017 ГОДУ ИСПОЛНЯЕТСЯ 90 ЛЕТ

БТИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ОТРАСЛИ ТЕХНИЧЕСКОЙ ИНВЕНТАРИЗАЦИИ!

Поздравляем ветеранов-инвентаризаторов, которые создали фундамент современного предприятия БТИ Республики Татарстан, коллег, партнеров по бизнесу и заказчиков.

Приглашаем в БТИ Республики Татарстан. Предприятие имеет подразделения во всех районах республики. Информацию об адресах приемных зон и телефонах вы можете уточнить на сайте bti.tatarstan.ru.

- ТЕХНИЧЕСКИЙ ПАСПОРТ И ТЕХНИЧЕСКИЙ ПЛАН
- МЕЖЕВАНИЕ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ
- ПРОЕКТИРОВАНИЕ, РЫНОЧНАЯ ОЦЕНКА
- ЭНЕРГОАУДИТ, СУДЕБНАЯ ЭКСПЕРТИЗА
- ЮРИДИЧЕСКОЕ СОПРОВОЖДЕНИЕ ОФОРМЛЕНИЯ НЕДВИЖИМОСТИ

РЕКЛАМА

Яңа һәм кулланышта булган металл (пенал) гаражлар сатабыз. Теләсә нинди үлчәмдә.
Китереп бирү бушлай. Бәясе 27 мең сумнан башлана. Тел.: 8-800-700-90-91
Реклама

АФИША
22-28 МАЙ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

22 май «Хафалы биюләр» (С.Юзеев)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 300-350 сум
22 май «KAZAN» бию ансамбле
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 500-1500 сум
23 май «Ак калфагым төшердем кулдан» (И.Юзеев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
24 май «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт, С.Ваннус)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
25 май «Дон Жуан» (Ж.Б. Мольер)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
26 май «Без китәбез, сез каласыз» (Т.Миңнуллин) (КДМИ студентларының диплом эше)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 100 сум
26 май «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф. Бүләков)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
27 май «Илдус Габдрахманов – юбилей кичәсе»
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум
28 май «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р.Мөхәммәтшин)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 300 сум
28 май «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р.Мөхәммәтшин)
Башлана: 12.25
Билет бәясе: 300 сум
28 май «Галиябану» (М.Фәйзи)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

22 май «Өченче булмәдә эт яши» (Р.Мингалим)
Башлана: 18.30
23 май «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова)
Башлана: 18.30
24 май «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
Башлана: 18.30
25 май «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов)
Башлана: 18.30

28 май «Өзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 300-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

27 май «Хаврошечка» (Л.Савчук)
Башлана: 11.00, 13.00
28 май «Теремок» (С.Маршак)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 200-300 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

22 май «Мунча ташы»
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1200 сум
25 май «Казан кичләре»
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 500-1200 сум

УНИКС
(ПРОФЕССОР НУЖИН УРАМЫ, 2)

«Алтын Билбау»
Татарстан Республикасының сугышчан сәнгать буенча милли премия тапшыру чарасы
Башлана: 13.00
Билет бәясе: 100-200 сум

«ТУЛПАР» СПОРТ КОМПЛЕКСЫ
(Р.ГАРЕЕВ УРАМЫ, 80)

Йөгерү буенча бушлай мастер-класс
Башлана: 19.00
Керү ирекле

МЕГА СӘҮДӘ ҮЗӘГЕ
(ҖИҢҮ ПРОСПЕКТЫ, 141)

27 май «Яшел фитнес»
Башлана: 18.00
28 май «Яшел фитнес»
Башлана: 10.00
Керү ирекле

«КРЫЛЬЯ СОВЕТОВ» ПАРКЫ

Скандинав йөреше фестивале
Башлана: 11.00
Керү ирекле

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

СПОРТ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Казан Россиянең иң яхшы йөгерүче башкаласы булырмы?

21 май көнне узачак Казан марафонында быел 10 меңгә якын кеше катнаша. Спортчылар дүрт аралыкта (42,2 чакрым, 21,1 чакрым, 10 чакрым, 3 чакрым) көч сынаша. Марафон шәһәрнең иң гүзәл урыннарының берсе – Меңьеллык мәйданыннан башлана.

Экология елы уңаеннан керемнең бер өлеше Ак барсны саклап калу өчен тотылачак. Бу җанвар Татарстан өчен дә тарихи кыйммәткә ия. Узган ел «Казан марафоны» ВИЧ/СПИД авырuларына каршы булган иде. Быел да ул бу юнәлештә тугры булып кала. 19-21 май көннәрендә марафон кысаларында «Стоп ВИЧ/СПИД» Бөтенроссия акциясе чаралары узачак. Бу көннәрдә Казанның Үзәк стадионының манеж бинасында теләге булган һәркем ВИЧ/СПИД профилактикасы турында мәгълүмат ала, шул ук вакытта «Җиңү өчен тест. Test to win» зонасында интерактив чараларда катнаша һәм мобиль пунктта ВИЧ-инфекциягә бушлай аноним экспресс-тест узa ала. Ә марафон көнендә проект Казан кирмәне диварлары астындагы старт шәһәрчегендәге инфопалаткада һәм тест узудыру пунктында дәвам итәчәк.

Һәр катнашучыга спортчының тизлеген билгели торган номер язылган чип, истәлеккә футболка, медаль тапшырачаклар. 42,2 чакрым аралыкка чыгарга батырчылык иткәннәрне исә токмачлы кичке аш көтә. Башка еллардан аермалы буларак, быел балалар өчен дә аерым дистанция билгеләнгән.

Бу көнне Казан йөгереп кенә калмый, ә ЗАБЕГ. РФ проектында да катнаша. Татарстан башкаласыннан тыш, Россиянең тагын ун шәһәре ярыммарафон һәм кыска дистанцияләргә баса. Проект нәтиҗәсендә илнең иң яхшы йөгерүче башкаласы билгеләнәчәк.

«Рубин» ЦСКАга оттырды

Җанатарлар да, футболчылар да көтеп алган матч җиңелү белән тәмамланды. 17 май көнне Россия чемпионаты кысаларында узган уенда Казан «Рубин»ы Мәскәүнең ЦСКА командасына 0:2 исәбе белән оттырды.

Моңа гаҗәпләнерлек тә түгел, чемпионат финишында казанлыларның җиңүгә омтылышы бөтенләй юк дәрәҗәсенә житте. Җиңсәләр – «Рубин»га иң яхшысы – җиденче, җиңмәсәләр – унынчы урын әләгәсе көн кебек ачык иде. Ә ЦСКАның Чемпионнар Лигасында көч сынашасы бар әле. Шуңа да кунаклар аеруча да тырышты. Хәзер ЦСКАның – «Зенит» (Санкт-Петербург), ә «Рубин»ның «Амкар» (Пермь) белән соңгы уены гына калды.

FIFA таләбе буенча «Рубин» – ЦСКА уены Конфедерация Кубогы алдыннан сынау матчы булды. «Казан-Арена» стадионы әзерләнгән, җанатарларны кабул итү пункты төзеклеген һәм шәһәр юл хәрәкәте ябылышын тикшерделәр. Матч карарга бушлай билет һәм Fan-ID җанатар паспорты белән 27 мең кеше килгән иде.

Соңгы вакытта иң популяр спорт төре – скандинав йөреше. Кала халкы да, саланыкы да кулына таяк тотып йөри хәзер.

Иң популяр спорт төре

Шулай булмый ни, ул бит гәүдәнең 90 процент мускулын ныгытырга сәләтле. Йөрәк, үпкә эшчәнлеген яхшырта. Муен, иңбашы авыруларын киметә, умыртка баганасын турайта. Башка спорт төрләре белән чагыштырганда, буыннарга көч китерми. Соңгы мәгълүматлар буенча, әлеге спорт төре белән Россиянең 4 миллион кешесе даими шөгыльләнә.

Татарстан халкы да ил күрсәткечләреннән калышмый. 27 май көнне Волгоград, Новосибирск шәһәрләре белән берррәттән, Казанда да скандинав йөреше фестивале узачак. «Хәрәкәт ирегә» дип аталган чара «Крылья Советов» паркында үткәрелә.

Фестивальдә катнашу өчен, паркка спорт киеменнән килергә кирәк. Таякларны шунда ук прокатка алып торып булачак. Скандинав йөреше белән әле таныш булмаганнар өчен 11 сәгать 30 минутта инструктор дәрес үткәрә. Тәҗрибәлерәк катнашучылар исә 13 сәгатьтә узара ярыша да ала. Җиңүчеләрне 50 яшькә кадәр, 51-60 яшь, 61-70 яшь, 71 яшьтән олырак яшь категорияләрендә бүләкләячәкләр. Физик яктан гына түгел, рухи яктан да ныгып кайтачак бу көнне ярышучылар. Спорт өлешеннән тыш, интеллектуаль ярышлар да үткәрелә.

Өстәмә мәгълүмат өчен телефон: 8-800-222-04-58.

Йөгергәндә сәгатенә 500 килокалорий яна, тән мускулларының 40 проценты эшли. Скандинав йөрешендә 700 килокалорийны югалтасың, 90 процент мускул хәрәкәткә килә.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1646. Гомуми тираж – 6043.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 714. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы